

## Нигәме? Чөнки!

«Тәнкыйть дигән нәрсәне кемнеңдер кемнедер нәрсәгәдер өйрәтергә тырышуы дип кабул итәм. Бигрәк тә тәнкыйтьләүче тәнкыйтьләнүчедән үзе өйрәтә торган өлкәдә остарак, тәҗрибәлерәк булса. Яки, әйтик, үзенең эшләгән эшләре арасында: «Мә, менә кара, шулай эшләргә кирәк аны», – дип әйтерлек казанышлары булса. Ә юк икән – монысы инде тәнкыйть түгел, ә бары тик эшләгән кешене ничек булса да кимсетергә тырышу, татарның борынгыдан килгән әйтемендәгечә, бөрмәдән бет эзләү генә».

4 БИТ




## «Зөләйха күзләрен ача»

### Популяр әсәр – татарча

«Йә инде, Зөләйха, җебегән тавык, атла, атла әйдә. Үзең беләсең: чанадан аерылып артта калсаң – бетәчәксең. Мортаза сизми дә калачак. Урманда катып үләчәксең. Ни дисәң дә, нинди яхшы кеше бит ул – аны эзләп килде, тапты. Урман эчендә калдырып та китә ала иде – кемдә кемнең ни эше бар: исәнме ул, юкмы. «Урманда адашып калды, тапмадым», – дияр иде. Бер көннән соң аны беркем дә искә алмаган булыр иде. Карале, күзне йомган килеш тә атлап була икән бит. Болай җайлырак та – аяклар йөри, күзләр ял итә».

11 БИТ


1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

# Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 28.01.2016 | № 8 (5626)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ


# ӘБИЛӘР ДӘ, БӘБИЛӘР ДӘ ТАУ ШУА

**Авыл халкының тормышы эш белән эш арасында гына диючеләр ялгыша. Ял итәргә дә, спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт таба алар. Әнә Саба районының Эзмә авылы өч республика чемпионын тәрбияләп үстергән. Мишә елгасында су кереп, Калатауда чаңгы шуып чыныгып үскән балалар әле тагын да зуррак җиңүләргә ирешер.**

8 БИТ




Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы



Җырла, җырла, дип әйтәсез... Сезгә нинди гимн кирәк?

7 БИТ



Резеда Шәрәфиева: «Көнчелек турында уйлап, вакыт әрәм иткәнем юк»

9 БИТ

## РЕСПУБЛИКАДА

**ӘЛМӘТ**

Әлмәттә яшәүче беркайда да эшләмәүче бер ир-атның алимент бурычы 1,5 миллион сумга җыелган. Татарстан Суд приставлары идарәсе хәбәр итүенчә, аның милке дә юк. Шуңа да алимент түләүдән качып йөрүчене машина йөртү таныклыгыннан мәхрүм итәргә булганнар. Әлеге карар ЮХИДИ идарәсенә җибәрелгән.

**ТҮБӘН КАМА**

Түбән Кама хәрби комиссариатында кыз кеше армиягә барырга җыена.

Инга Шуйская Түбән Кама технология көллиятендә укыган, автомат күрсә, тизрәк аны сүтеп җыю теләге белән яна, диләр аның турында яшьтәшләре. Инга, килешү буенча, хәрби хезмәткә барачак.

**НУРЛАТ**

Нурлат районының Егоркино авылыннан Анатолий Трофимов теплица төзергә җыена. Быелтыр ул «Яшь фермер» программасы буенча грант откан булган. Шул акчага тулысынча автоматлаштырылган теплица төзи башлаган. Теплицаның мәйданы – 500 квадрат метр, ди. Яз көне фермер яңа теплицада кыяр һәм помидор үстерергә җыена. Яшелчәләрне ул ачык грунтта да үстерергә хыяллана.

**ЯШЕЛ ҮЗӘН**

Дәү әнисе янына барырга җыенган җирдән буранда адашкан Егор турында язган идек. Яшел Үзәндә 9 яшьлек бу малайга ярдәм итү өчен акча җыю оештырылган. Хәзер баланың сәламәтлеге яхшыра бара, ди табиблар.

**Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.**

# Кешеләрне тотрыклы хезмәт хакы белән тәэмин итәргә кирәк

**Эльвира МОЗАФФАР**



president.tatarstan.ru

– Бүгенге көндә Татарстанда эшсезлек буенча хәл зарланырлык түгел. 16 мең эш эзләүчегә 24 меңнән артык вакансия туры килә. Ягъни бер эшсезгә ике эш урыны тәкъдим итәргә була дигән сүз. Россия Федерациясе 2016 елда кризиска каршы чаралар программасы әзерли. Узган ел тәҗрибәсеннән чыгып, без дә үз тәкъдимнәребезне керттек, – ди Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова.

Әлеге өлкәдә эшләнгән эшләргә йомгак, киләчәккә планнар турында министрлыкның киңәйтелгән коллегия утырышында сөйләштеләр. Чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

2015 елда социаль икътисади яктан катлаулы хәл күзәтелсә дә, министрлыкның эшен югары бәяләделәр. Былтыр чынлап та аз эшләнмәгән. 80 меңнән артык эш эзләүченең 49 меңнән артыгын эшкә урнаштырырга ярдәм иткәннәр. Физик яктан мөмкинлекләре чикле кешеләргә хезмәт урыннары булдырганнар. «Уңайлы мохит» программасы уңышлы эшләп килә. Каникул еллары вакытында яшүсмерләргә акча эшләү мөмкинлеге тудырылган. Хезмәт куркынычсызлыгы өлкәсендә дә 1,5 процентка үлем очраклары кимегән. WorldSkills Competition һөнәрчеләр чемпионатын уздыру мөмкинлеген ялау, футбол буенча чемпионат үткәрү хокукын алу дисеңме... Татарстан дөнья күләмендә чемпионатларны югары дәрәҗәдә, уңышлы уздыра алуын дәлилләде. Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты моның ачык мисалы булып тора. Әлеге чараны 6 миллиард кеше күзәтте бит. Бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та искәртеп үтте.

Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан да Татарстанда күп чаралар узды. «Әлмәт шәһәрләре волонтерлары» иҗтимагый хәрәкәте җитәкчесе Айсылу Насыйрова үзләрендә булганнары белән таныштырды. Әйтик, анда «Көчтәнәч» акциясе кысаларында, студентлар 200ләп ветеранны үзләре пешергән тәм-томнар белән дә сыйлаган, бәйрәм котлаулары җиткергән. Коллегиягә Советлар Союзы Герое 90 яшьлек Борис Кузнецов та килгән иде. Аның ялкынлы чыгышыннан соң, Рөстәм Миңнеханов:

– Сезгә хас дәрт, энергия 20 яшьлекләрдә дә юктыр, – дип, Геройны алкышлады. – Нефть бәясе төшү белән бәйле икътисади яктан тотрыксыз вазгыять иртәгесе көнгә ышанычны киметсә дә, иң мөһиме: төп капиталга инвестицияләр 600 миллиард сум күләмендә кертелде. 32 дәүләт программасы эшләп килә. Балалар бакчалары төзелә, мәктәпләр төзекләндерелә. Демографик хәл сөендерә. Туучылар саны артты. Гаиләне ныгытуга зур игътибар бирергә кирәк. 2015 ел бик авыр булыр дип фаразланган иде, Федераль дәүләттән күрсәтелгән ярдәмнең файдасы сизелде. Бу ел да җиңел булачак дип вәгъдә итеп булмый. Тәнкыйтьләр, вәгъдә бирүләр, сайлаулар булыр, кимчелекләребез дә күренер. Бу авыр чорны, социаль басымны үткәрергә, бердәм булырга кирәк. Кешеләрне тотрыклы хезмәт хакы белән тәэмин итү мөһим.

Коллегия азагында социаль яклау өлкәсендәге хезмәт алдынгыларын тырыш хезмәтләре өчен медальләр белән бүләкләделәр, министрлыкның ведомствоара учреждение җитәкчеләренә машина ачкычлары тапшырылды.

**1,74 млн** Татарстанда 1,74 миллион кеше дәүләттән социаль ярдәм ала.

## Шәһәр кәефе



**РӨСТӘМ КУЛИЕВ,**
журналист:

– Киров районындагы ике катлы агач йортта бала чагым, мәктәп елларым узды. Агачтан салынган өйләрнең рухы җылы. Хәзер Яңа Савин районында яшәсәм дә, агач өйләрне, урамыбыздагы гаиләләрнең капка төпләрәнә чыгып утырып серләшүләрен сагынам. «Советский спорт» газетасының Казаннан тәүге үз корреспонденты мин булдым. Спортны яратам, Татарстан командаларының һәм спортчыларының уңышларына сөенәм.



**ГАЛИНА ШЛАКОВА,**
инспектор:

– Казанның элеккеге Ленин районында туып-үстем. «Ленин районыннан» дип әйтү заманында үзе бер горурлык иде. Өлкән яшьтәгеләр бүген дә шулай сөйләшә. Шәһәрнең 46 нчы мәктәбендә бергә укыган сыйныфташларны, чордашларны еш искә төшерәм. Узган җәйдә иркенләп Болгарга, Зөя утраушәһәрчегенә, Раифа монастырена сәяхәт кылдык. Байкал күленә җыйнаулашып сәяхәт ясарга хыял бар.



**РӘДИФ ФАЗЛЫЕВ,**
хезмәткәр:

– Мурманск өлкәсендә армия хезмәте узганнан соң Казанга кайттым. Армиягә кадәр монда эшләгән идем, Казан күңелне гел үзенә тартып торды. Ял көннәре якынлаша башласа, күңел туган авылым Ятмас Дусайга (Кукмара районы) ашкына. Универсиада вакытында төзелгән юл-транспорт чишелешләре миңа бик ошый. Машина сатып алам, дип, үз-үземә максат куйдым. Казанда хыял-максатларыңны тормышка ашырырга була.



**ИННА СИЛАНТЬЕВА,**
хезмәткәр:

– Туган шәһәрем Казанны башка бер җиргә дә алыштырмас идем. Бүгеннәрдә 24-26 градус салкын. Иптәшләремнең кайсылары: «Салкыннан туйдык», – дип зарланалар. Мин исә кышны һәм салкыннарны яратам. Салкынга тиз бирешүчеләргә җылырак итеп киенергә кирәк, әлбәттә. Җәйге айларда бакчабызда казыну җан рәхәте бирә. Татарстан, Казан табигатенең матурлыгын, сихәтен күрә белергә кирәк. Яшелчә орлыклары хәстәрләдем.



**ИЛЬЯС ФӘТТАХОВ,**
инженер:

– Васильево бистәсе малае мин, шунда тудым, шунда үстем, 1 нче мәктәптә белем алдым. Казанда авиация институтында радиоинженер белгечлеге үзләштердем. Радиоэлектроника, компьютер техникасы – минем стихия. Мин аларны җыям-сүтәм. Тагын төзелеш, агач-таш эшен яратам. Васильевода өйне үзебез күтәрдек. Бакчада чәчәк түтәлләрендә казынырга яратмыйм, анысы – хатынның дөньясы, ул җирдән гөлбакча ясап куя.

# Кочаклашма, үбешмә... грипп йөри

**Министрлар кабинетында үткәрелгән чираттагы утырыш битлекләр киюдән башланды. Татарстан сәламәтлек саклау министры, бары тик шулай гына илдә хөкем иткән грипп һәм салкын тию авыруларыннан сакланып булачак, ди.**


kazan.kp.ru

**Алисә САБИРОВА**

Быел грипп инфекциясенең иң көчле дулкыны февраль аена туры киләчәк. Табиблар көндәлек гигиена таләпләрен үтәргә, кеше күп булган җирдә йөрмәскә, авыру кешеләр белән кочаклашмаска, үбешмәскә, кул биреп күрешмәскә киңәш итә. Урамнан кергәннән соң да кулларны һәм борын куышлыгын яхшылап сабын белән юарга кирәк.

– Россиянең 13 төбәгендә эпидемия чиген артып китте, әлеге исемлектә Татарстан юк. Бу вакытында тиешле прививкалар ясатылу белән бәйле. Гыйнварның икенче атнасыннан авыручылар саны республикада да арта башлады. Ләкин бу көтелмәгән хәл түгел, ә сезонлы күренеш. Республикада бүген дуңгыз гриппы белән – 14 (7 – бала, 4 – йөкле хатын-кыз), тын юлларының үтә көчле вирус инфекциясе белән 16 меңгә якын кеше авырый, – дип белдерде Россия Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең ТР буенча идарәсе башлыгы Марина Патяшина.

Дуңгыз гриппы шуның белән куркыныч, ул бер-ике көн эчендә өзлегүгә китерә. Вакытында дәваланмаган очракта, органнар ялкынсынуына, пневмониягә китерергә мөмкин. Балалар, йөкле хатыннар, өлкән яшьтәгеләр, шикәр авыруы һәм симерүдән интегүчеләр куркыныч зонасында. Шуңа да белем бирү учреждениеләрендә 25 гыйнвардан зур чаралар үткәрү тыелган. Грипп эпидемиясе аркасында, Аксубай районы, Яңа Ибрай урта мәктәбендә VIII сыйныфта укулар вакытлыча туктатылган.

– Авыруның таралуы һава торышыннан да тора. Урамда 15-20 градус салкын булса, вирус таралу мөмкинлеге кими. Җылы, дымлы һава, киресенчә, эпидемия таралуга сәбәпче. Йөткергәндә һәм төчкергәндә әдәп кагыйдәләрен искә төшерү дә комачау итмәс. Төчкергән вакытта авызны кулъяулык белән капларга, соңыннан, мөмкинлек булса, кулны яхшылап сабын белән юарга кирәк. Гомумән, бу көннәрдә кулны гел сабынлап юыгыз, антисептик гельләр кулланыгыз, – ди Адел Вафин.

Үзеңнең генә түгел, айпад, смартфоннарның, хәтта телевизор пультының да чиста булып торуы зарур. Көн саен аларны бактерияләргә каршы булган салфеткалар белән сөртергә киңәш ителә.

Грипп таралу куркынычы көчле булганлыктан, Казан һәм Бигеш аэропортларында да бу көннәрдә бигрәк тә куркыныч зона саналган территорияләрдән килгән кешеләрне күзәтәчәкләр. Хастаханәләрдә дә авыруларның хәлен белү вакыты чикләнә.

**Сүз уңаеннан, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматлар буенча, башлангыч сыйныф укучыларына һава температурасы шәһәр җирендә 25 градус һәм аннан салкынрак булганда, авылда исә 23 градустан түбән булганда мәктәпкә килмәскә мөмкин. 5-9 нчы сыйныф укучылары өчен авылда -25, шәһәрдә -27 градус булганда, өлкән сыйныфларга -30, -32 градус салкында мәктәпкә бармаска рөхсәт ителә. Бу очракта укучы дәресләрне сәбәпсез калдырган булып саналмый.**

**Россия халкының финанс яктан белеме бик сай икән. Самарадагы «Волга-Кредит» банкы җитәкчелеге күп кенә клиентларын төп башына утыртып, акчаларын урлаган. Әгәр халык финанс механизмнарның нигезен белгән булса, мондый күңелсез очрак килеп чыкмас та иде.**

# Фатирны сатып алыргамы, арендаларгамы?

Татарстанның Милли банкында видеоэлемтә аша, Россия Банкы рәисе урынбасары Владимир Чистюхин катнашында, киңәшмә узды. Анда 2016-2018 елларга илнең финанс базарын үстерүне күздә тоткан документ проекты буенча фикер алыштылар.

Документта халыкның финанс грамоталылык дәрәҗәсен арттыруга зур игътибар бирелгән. Күпсанлы сораштырулардан күренгәнчә, кешеләрнең күпчелеге финанслар өлкәсендә гадәти әйберләрнең дә асылын белми.

– Югары класс укучылары өчен финанс грамоталылык буенча аерым дәрес кертергә уйлаган идек, әмма Россиянең Мәгариф министрлыгы безне бераз шелтәләп алды. Балаларның болай да укудан башы чыкканы юк: өстәмә рәвештә юл хәрәкәте иминлеге, тирә-як мохитне саклау дәресләре дә кирә, диләр. Шуңа да карамастан, җәмгыять белеме курсының икътисад бүлегендә берничә дәресне финанс белеменә багышларга килештек. Укыту-методик комплект әзер, анда дәреслек һәм укытучыларга әлеге дәресне ничек алып барырга кирәклеге турында белешмәлек тә бар, – дип аңлатты Россия Банкы рәисе урынбасары.

Яңа дәрес 2017 елның 1 сентябреннән мәҗбүри укытылачак. Ә 2016 елдан кайбер төбәкләрдә сынау рәвешендә дәресләр үткәреләчәк, исемлекне Россиянең Мәгариф министрлыгы әзерли. Укытучыларга яңа дәреснең асылын быелдан төшендерә башлаячаклар.

Халыкның финанс белемен күтәрү максатында, 2017 елдан сайт та ачылырга тора.

– Анда яшәешебезнең күп кенә өлкәләрен колачлаган сорауларга җавап биреләчәк. Мисал өчен, фатирны арендалау яки сатып алу отышлыракмы? Акчаны җыяргамы, әллә кредит алыргамы? Чит илләрдә мондый сайтлар халык арасында бик популяр, бик гади һәм аңлаешлы ясалган, – диде Владимир Чистюхин.

**Линар ЗАКИРОВ.**

## ТОП – 5

**РОССИЯ** ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин әйтүенчә, республикадагы иллегә якын мәчетте имамнар юк, күп имамнарыбызның дини белеме булмавы да борчый. Институт галимнәре әлеге мәсьәләләрне чишүдә ярдәм итәргә әзер.

**ТАТАРСТАНДА** иң гүзәл кызны сайладылар. «Татарстан гүзәле» титулына Казаннан 18 яшьлек Диләрә Ялалетдинова ия булды. Ул «Мисс Россия» бәйгесе финалында Татарстан данын яклаячак. 21 яшьлек Софья Мостафина «Казан гүзәле» исеменә лаек булды.

**ЧУВАШИЯДӘ** чаңгы сезоны ачылышында Юван урта мәктәбеннән җиденче сыйныф кызы ике чакрым арасы узып, икенче урын яулый. Ләкин бүләкләү тантанасы вакытында ул, аңын югалтып, карга егыла. Шуннан бирле комада икән. Кыз исә чаңгыда чыгарга теләмәгән, хәле булмаудан зарланган, сыйныф җитәкчесе үгетләгәч кенә тыңлаган. Хәзер бу вакыйга буенча тикшерү эше бара.

**М-7** трассасында төнлә юлчыларның йөк машинасы ватыла. Шофер үзе һәм хатыны туңа башлагач, 112 коткару хезмәтенә шалтырата. Коткаручылар өши башлаган гаиләне тизрәк якындагы кунакханәгә илтә. Узган елның 17 ноябреннән быелның 25 гыйнварына кадәр республикада 10 кеше өшеп үлгән.

**КПРФ** депутатлары Россия Дәүләт Думасына яңа канун проекты тәкъдим иткәннәр. Март аеннан башлап аз керемле гаиләләргә азык-төлек һәм беренче чиратта кирәк булган товарларга айлык акча түләргә кирәк дигән фикерне җиткерә алар. Россиядә моның өчен ай саен 156 миллиард сум акча кирәк, ди. Бу акчаны кайбер бюджет чыгымнарын киметеп һәм хәлле кешеләргә керем салымын арттырып тупларга тәкъдим итәләр.

# Кама Тамагы районы башлыгы клипта төшкән

Кама Тамагы районы башлыгы Павел Лоханов «Камский судак» дигән җырга клип төшергән. Әлеге клип бик тиз арада социаль челтәрләрдә таралып, күп лайклар җыярга өлгерде. Видеоклипта район җитәкчесе судак турында шәхсән үзе җырлый. Шунда ук алтын балык турындагы татарча җырны да кушып җибәрә. Павел Лоханов җыр аша туристларны һәм балыкчыларны Кама Тамагына судак тотарга чакыра. «Волга-река зовет сюда – знает каждый рыбак. Кама-река манит сюда. Заветный судак», – дип җырлый район башлыгы. Туристларны районга җәлеп итүнең шундый креатив юлын уйлап тапкан җитәкченең тырышлыгын бәяләми калмаслар. Әлеге җырны тыңлаганнан соң, ничек инде Кама Тамагы районын барып күрми түзәсең. Барган барган балык та тотып карыйсы килер.

**Сүз уңаеннан:** Павел Лоханов белән клип һәм балык тотуга һәвәслеге турында сөйләшә алмадык, район администрациясеннән безгә видеоязманың социаль челтәрләргә очраклы рәвештә эләгүен, чынлыкта аның шәхси архив өчен генә төшерелгәнен әйттеләр. Район халкы клипны үзе дә бик теләп караган һәм аңа зур бәя биргән.

Павел Лоханов район белән узган елның февраленнән җитәкчелек итә. Райондашлары аның спортка, яшьләр сәясәтенә уңай мөнәсәбәтен югары бәяли. Үткән елны Идел ярында яшьләр өчен ачык һавада дискотека оештыру идеясе белән дә чыккан башлык. Тиздән районда кино да төшерергә ниятлиләр икән.

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.**

**Тәнкыйть дигән нәрсәне кемнеңдер кемнедер нәрсәгәдер өйрәтергә тырышуы дип кабул итәм. Бигрәк тә тәнкыйтьләүче тәнкыйтьләнүчедән үзе өйрәтә торган өлкәдә остарак, тәҗрибәлерәк булса. Яки, әйтик, үзенең эшләгән эшләре арасында: «Мә, менә кара, шулай эшләргә кирәк аны», – дип әйтерлек казанышлары булса. Ә юк икән – монысы инде тәнкыйть түгел, ә бары тик эшләгән кешене ничек булса да кимсетергә тырышу, татарның борынгыдан килгән әйтемендәгечә, бөрмәдән бет эзләү генә.**



# НИГӘМЕ? ЧӨНКИ!

Илфак ШИҺАПОВ

Соңгы арада интернет челтәрендә "Яңа Гасыр" телеканалы эшчәнлеген, эфирга чыккан тапшырулар, сериаллар һ.б.ны аноним рәвештә тәнкыйтьләргә тырышу кебек оештырылган күренеш сизелә. Сүз дә юк, бардыр әлеге каналның йомшаграк урыннары, тәнкыйтьләр урын да бардыр. Тик менә ниндидер анонимнар битлеге артына качып, татар телевидениесенә пычрак атучылар, нигездә, үзләренең ниндидер сәбәпләр белән яратмаган кешеләренә яки әзер продуктка түгел, ә гомумән, ТАТАР телевидениесенә таш атуларын аңлыйлармы икән?! Әллә бу бары тик кемдер режиссерлык иткән бер чара гынамы? Аптыраган, чуаш әйтмешли... Ләкин тегеләй булса да, болай булса да, бүген «Яңа Гасыр» телеканалы җитештергән продуктны аноним рәвештә яманлап язучылар коймага әшәке, ниндидер пычрак сүз язган малайны хәтерләтә. Телевидение булсын, ул эшләсен дип янып йөрүчеләргә карата ниндидер начар сүзләр язучыларга мин бер генә сорау бирер идем: «Ә сез үзегез берәр нәрсә эшләп карадыгызмы соң?»

Берничә ел элек Оренбург өлкәсенең Казахстан белән чиктәш урнашкан Озерки авылына барып чыгарга туры килде. Далада, тиле әйтмешли, бәрәңге дә үсми торган җирдә урнашкан авылда мине иң гаҗәпләндергәне – авылның чеп-чи татарча яшәве. Кибет диварына кулдан язып ябыштырылган «Сыер сатам», «Кер юу машиналары ремонтлыйм» кебек шәхси белдерүләр дә чиста татарча язылган иде ул авылда. Юк, монда татар мәктәбе дә эшләми, тик олысы-кечесе татарча сөйләшә. Мине гаҗәпләндергән бу хәлнең асылын өч баласы да теттереп татарча сөйләшүче бер апа аңлатты: «Соң, бала-

## МИН ШУЛАЙ УЙЛЫЙМ

каем, телевизорыбыз татарча сөйләп тора бит...» Менә шул сүзләрдән соң миндә: «Безнең татар телевидениесе шулай, безнең татар телевидениесе тегеләй...» дигән тәнкыйди уйлар бетте дә куйды. Нигәме? Чөнки. Телевидениене сүгәр алдыннан, аның тапшырулар программасын булса да (шул ук интернетта бар) кереп карасыннар иде сүгүчеләр. Яки үзләре, ичмасам, бер биш кенә минутлык телетапшыру эшләп карасалар иде. Тик ни эшләтәсең... Әле берничә ел элек кенә: «Татар әдәбиятының гүзәл үрнәкләрен экранлаштырсалар иде», – диючеләр шул ук «Ак чәчәкләр»нең экранлаштырылган вариантын сүгеп ята, «фәлән тапшыру фәләнчә чыкса иде», – дигәннәр тапшыруларны тәнкыйтьли, «элекке җырлар күбрәк яңгырасын иде», – дип лаф оручылар даими рәвештә элекке җырлар яңгырап торган музыкаль тапшыруларны сүгә. Нигәме? Чөнки сәбәп телевидениедә түгел, безнең үзебездә. Шундый без: эшләгәнне сүгәргә, шул сүгү аша булса да үзебезнең «важный»лыгыбызны күрсәтергә яратабыз. Әлбәттә, «бар да яхшы» дип утыру да һәрвакыт яхшы түгел, тик менә Миләүшә Айтуганова, Илшат Әминов кебекләрнең эшеннән тап эзләгәнче, алар эшләгәннең йөздән берен генә булса да эшләргә иде бит, иптәшләр. Яки, һич булмаса, бер көн бүгенге татар телевидениесен җитди итеп башка берәр милли телеканал белән чагыштырып карарга иде. Яки эшләрлек кешеләрнең исемнәрен китерергә иде. Курыкмыйча, аноним кулланмыйча. Әлбәттә, андый белгечләр барлыгын белсәгез. Тик юк бит... Әлбәттә, русча федераль каналлар күп, диванда телевизор пультын тотып утырганда, аларның төрлесеннән үзеңнең күңеләңә килгән тапшырулар табып буладыр ул. Тик бүген безнең бөтен татарны берләштереп тора ала торган татар телеканалы әлегә бер генә – ул «Яңа Гасыр». Барысы да бар анда: тарихи тапшырулар да, яңалыклар да, мәдәният тә, башкасы да... Әйе, халкыбызның, әз генә мулла кызында да була, дигән әйтемендәгечә, эшләгән кешенең эшеннән кимчелек табарга һәрвакыт була инде ул. Тик менә шул кимчелек эзләүнең әлегә яхшының-начарны эшләп килгән, телисезме-теләмисезме, үсештә булган татар телевидениесенә һәм, асылда, гомумән телебезне саклап, татарны берләштереп торган бердәнбер нәрсәгә кизәнү икәнен аңлыйсызмы икән соң сез, исемнәрен яшереп, телевидениене сүгеп ятучылар?! Ниндидер рейтинглар турында сөйләгәнче, татар яши торган районнар, авыллардан сорашсагыз иде анда ни караганнарын. Татар яши торган чит өлкәләрдә сорашсагыз иде...

Без урамнан үткән машинага койма артыннан өреп калган этләр кебек, күренмичә генә өрергә яратабыз. Һәрхәлдә, интернетта телевидениене әрләп язган комментарийларны укыгач, миндә шуннан башка фикер тумый. Тик күпме генә эзләсәм дә, шул комментарийлар арасыннан нәрсә эшләргә, ничек эшләргә кирәген күзаллаучы бер генә фикер дә тапмыйм. Ә бит иң мөһиме шунысы...

## Сүзен-сүзгә



**Фәндәс САФИУЛЛИН,** җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче:

– Халыкларның алга китешендә бердәнбер чын критерий булып аларның рухи, интеллектуаль, мәдәни үсеш дәрәҗәсе тора. Мәдәниятнең җимерелүе – иң зур куркыныч кризис, җәмгыятьтәге барлык бәлаләрнең башлангычы. Коммерциянең мәдәнияттән өстен куелуын берничек тә аклап булмый, мәдәниятка күңел ачу чарасы итеп кенә карау дөрес түгел. Мәдәният өчен куркыныч корал ул – культура белән коммерциянең кушылуы. Шул рәвешле мәдәният сүрелә, сүнә, агрессив, халык күңелен үтерә торган бер көчкә әверелә.

«Яңа Гасыр» каналын сүгү мәгънәсез, минемчә. Җитәкчеләр үз эшләрен беләләр, эшлиләр. Тик, гадәттә, мәдәният коммерциягә табыш китерми.



**Разил ВӘЛИЕВ,** Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе:

– Бездә, татарларда, күңелгә ятмый торган бер гадәт бар: мактыйлар икән, үтереп мактыйлар, тәнкыйтьлиләр икән, үтергәнче сүгәләр. Ә бит дөреслек уртада ята. Билгеле, мин «Яңа Гасыр» телевидениесен идеаль димим. Ләкин аның җитешмәгән якларын әйтеп, дөресләргә кирәк урыннарын аңлатып, тикшерү үткәрсәләр, дөресрәк булыр иде. Мин статистикаларга, социаль тикшеренүләргә бик артык ышанып бетмим. Әгәр авылга, татар районнарына, татарлар яшәгән чит төбәкләргә барам икән, анда «Яңа Гасыр»ны күккә чөеп мактыйлар, һәммәсе татар телевидениесен карый. Әйе, телевидениедә үзешчән җыр-биюгә зур урын бирелә, профессиональ мәдәният аз, сәяси тапшырулар юк диярлек, тарихка кагылышлысы да җитәрлек түгелдер бәлки. «Яңа Гасыр» каналы бары тик татар телендә генә булырга тиеш дип саныйм. Гомумән, телевидениеме, сәнгатьме, әдәбиятмы – әгәр игелекле ният белән эш алып барыла икән – бу төрле яклап искә алынырга тиеш. Сугып егарга тырышу дөрес түгел.



**Фәннур ГАЙСАРОВ**, Оренбург өлкәсендә чыга торган «Яңа вакыт» газетасының баш мөхәррире:

Безнең өчен «Яңа Гасыр» каналы – барлык татарларны берләштерә торган, кадерле, кирәкле канал. Безнең якларда нәкъ менә «Яңа Гасыр» каналын карый алыр өчен авылларга кабельләр үткәрәләр, Озерки дигән бер борынгы авыл, хәтта халык белән җыелышып, татар каналын карау өчен, авылларына махсус җайланма да куйдыртты. Интернет аша күпме кеше карый татар тапшыруларын. «Яңа Гасыр» телевидениесе бакчасына таш ату, минемчә, бөтенләй ахмаклык. Төрле фикер бардыр, тик читтәге татарлар өчен «Яңа Гасыр» – милләткә, татарлыгыбызга якынайта торган бердәнбер канал. Татарстан белән элемтәләрне ныгыта торган күпер.



**Ирек ШӘРИПОВ**, Татарстан Халыклар дуслыгы йорты директоры, Татарстан Дәүләт Советы депутаты:

– «Яңа Гасыр» ул – бердәнбер татар телле аудиториясе булган үзенчәлекле канал, максатлары да башка, үз дәүләтчелегебезне күрсәтә, киләчәгебезне кайгырткан, алдагы көнне күздә тотып эшли торган канал. Аны коммерция нигезендә эш алып бара торган каналлар белән чагыштыру урынлы түгел. Без эшчәнлегебез буенча Россия төбәкләрендә күп булабыз. «Яңа Гасыр»ның аудиториясе – республикабызның шәһәр, авыллар халкы гына түгел, ул бөтен татар халкының аудиториясе һәм «Яңа Гасыр»ның үз аудиториясендә рейтингы бик зур.

# Трактор үзеңнән акыллырак булса...

**Татарстан хуҗалыкларындагы тракторларга акыл керә башлаган. Хикмәт шунда: 2010 елдан аларга GPS белән ГЛОНАСС навигацияләү системаларын урнаштыралар. Икесенең дә максаты бер – объектның урынын һәм вакытын төгәл ачыклау, әмма беренчесе – Америкада, икенчесе үзебездә чыгарыла.**



Илдар Мөхәммәтҗанов фото архивыннан

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының агросәнәгать комплексын инженерлык техникасы белән тәэмин итү бүлеге мөдире Ришат Булатов «ШК»га сөйләвенчә, компьютердан GPS белән ГЛОНАСС куелган техниканың бөтен нәрсәсен күреп була: нинди тизлек барганын, күпме ара үткәнен, кайда иконлеген... Тик кенә торганы беленсә, бер-бер хәл булмадымы, дип, тракторчы белән элемтәгә керәләр.

– Параллель йөрү системасы куелган тракторлар туп-туры итеп сөрә, культивация алып бара. Кәефкә карап, тракторчы начар сөрергә, орлыкларны өсте-өстенә чәчеп китәргә мөмкин, ә бу система мондый чаталыкларны булдырмый кала. Күзең күрмәсә дә, «акыллы» техника белән караңгыда да эшләргә була, ул «автопилот» кебек йөри. Әмма тракторчы да игътибарлы булырга тиеш, чокыр-чакыр, тимер-томыр килеп чыкса, ул техниканы борып җибәрә, – дип сөйләде Ришат Нурфаязович.

GPS белән ГЛОНАСС акчаны экономияләргә дә ярдәм итә. Бүлек мөдире әйтүенчә, Түбән Кама районындагы «Бәхетле-Агро» агрофирмасы үзенең техникасына бер миллион сумга навигацияләү системасын куйдырткан. Шуның ярдәмендә, бер ел эчендә өч миллион сумны янда калдырганнар.

Республиканың Авыл хуҗалыгы министрлыгы хуҗалыкларны нидер алырга мәҗбүр итә алмый, һәркем юрганына карап тәпиен суза.

Әлки районында GPS белән ГЛОНАСС җиһазларын 90 йөк машинасының – 50сендә, 318 тракторның 123ендә очратырга мөмкин. Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең механизацияләү буенча консультанты Рафыйк Галләмов сөйләвенчә, Әлкидә төп ике инвестор бар: «Красный Восток» белән ООО «Хузангай». Икесе дә тракторларын «акыллы» итүгә акчаларын кызганмаган.

– GPS кулланылганчы, бер хуҗалык елына 20 тонна солярка тота иде. Система куелгач, елына 17 тонна китә башлады. Менә, өч тоннага экономия, дигән сүз. Бу шулкадәр яхшы система. Мәсәлән, К-700 йөртүчесе бакка 200 литр ягулык сала да кырга чыгып китә. Берәр кайда туктаса, шунда ук күреп була. Система бакта күпме дизель ягулыгы булганын да күрсәтә, шуңа күрә бер тамчы агызып булмый. Әгәр солярка-бензинның югалганын ачыкласалар, хезмәт хакыннан тотып калалар. Эшчеләр, алып булмый, дип зарланалар инде, һәркемнең бармагы үзенә таба кәкрәя бит, – диде Рафыйк Галләмов.

Минзәлә районындагы 101 йөк машинасы белән 324 трактор болай да «акыллы», күрәмсең, чөнки берсендә дә навигацияләү системасы юк. Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең механизацияләү буенча консультанты Илгиз Ханов сүзләренчә, ул бу вазифага күптән түгел генә күчкән. Әмма моңарчы юл системасында эшләгән, анда GPS белән ГЛОНАСС күбрәк кулланыла, ди.

– Җиһазларны куючы-куймау хуҗалыклардан тора. Зуракларында юк инде алар, кечерәкләрдән, бәлкем, бардыр. Кем белә инде аларны, – диде ул.

Мөслим районында да GPS белән ГЛОНАССка мөкиббән түгелләр. Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең механизацияләү буенча консультанты Гүзәл Мортазинга Әлкинең күрсәткечләрен әйткәч, «Алар бит башкалага якынрак», – диде. Булса соң...

– Бездә тикшерүчеләр болай да күп. Яңа система районндагы зур хуҗалыкларның барысында да бар. «Туган як» агрофирмасында да куйдылар, аның җитәкчесе Чаллыда утыра, шуннан да контрольдә тота ала, – дип сөйләде Гүзәл Мортазин.

Белгеч сүзләренчә, җиһазларны куйдыру мәсьәләсе, беренче чиратта, акчага барып төртелә. Җиһазда никадәр күбрәк функция булса, ул шулкадәр кыйммәтрәк тора.

– Параллель йөрү системасының бәясе – 80-90 мең сум. Аның белән йөргәндә, рәтләр арасында чөйләр калмый. Яз көне басуда кипмәгән урыннар була, трактор аларны калдырып үтә. Ә соңрак, ул җирләр кипкәч, экраннан карап, трактор белән шул урыннарны барып эшкәртәләр. Хуҗалыклар арасында GPS белән ГЛОНАССның уңай яклары, аларны куйдыру кирәклеге турында агитацияне даими алып барабыз, – диде Гүзәл Мортазин.

## Кәҗә приюты ачкан Морат Сираҗин:

# «Бәтиләрне батыралар»

**Югары Ослан районының атаклы фермеры Морат Сиражин тарафларыннан «кайнар» яңалыклар берсе артыннан берсе килеп кенә тора. Ел башында аңа ике «КамАЗ» чыршы китергәннәр, кәҗәләр өчен приют ачып җибәргән, шуның өстенә әле тагын йонлач дуңгызлар да асрый башлаган.**

Шушы хәбәрләргә ачыклык кертү ниятеннән, Морат Сираҗин белән элемтәгә кердек.

– Кәҗә тотучылар яңа туган бәтиләрне кирәкмәгән йөк буларак кабул итә, – дип сөйләп китте ул. – Хуҗа кешегә кәҗәнең сөте генә кирәк. Ә бәтиләр бөтен сөтне имеп баргач, хуҗаларга берни дә калмый. Кәҗә ике елдан гына сөт бирә башлый. Шуңа күрә бәтиләрне еш кына батырып үтерәләр. Гәрчә Европада ул диетик ит булып саналса да, безнең якларда базарда да, кибеттә дә кәҗә ите юк. Шул сәбәпле, быелтыр алар өчен приют ачып җибәрдем. Кеше китерә тора, үземнекеләр белән бергә 70 баш тулды инде.



aif.ru

Морат Сиражин сөйләвенчә, картлар кыш көне балалары янына шәһәргә китә, шул сәбәпле кәҗәләрен карый алмый. Җәй көне кайтуын кайталар, әмма тулы канлы авыл кешесе буларак түгел, инде дачниклар булып кына яшиләр. Шунлыктан ел әйләнәсе терлек асраучылар кимегәннән-кими.

– Кешеләр, малны бетереп, үзләрен бәхетле хис итә башлый, «моңа кадәр юләр булганбыз икән», дип уйлыйлар. Ә мал булгач, син гел аларга бәйләнгән: ялың да юк, балаларың янына башка шәһәргә дә бара алмыйсың. 70 нче елларда хөкүмәт шәһәр белән авыл халкын тигезләде. Ә хәзер авылларда, шәһәрдәге сыман, беркем бернәрсә асрамый, – дип фикерләре белән бүлеште фермер.

Яңа елдан соң Морат Сиражин хуҗалыгына ике «КамАЗ» чыршы китергәннәр. Бу хәл болай булган: ике эшкуар, арендага бина алып, сатуга дип шунда күп чыршы кайтарганнар, әмма сата алмаганнар. Шуңа да яшел чибәркәйләрне, әрәм итмәс өчен, фермерга китергәннәр.

– Чыршыларның сатылмыйча калуын ике нәрсәдән күрәм: йә халык ярлыланган, йә дини күзаллаулары ныгыган... Мөселманнар да, христианнар да Яңа ел бәйрәмен танымый. Татарларда чыршы Нардуган бәйрәмендә генә куелган. Ул кешеләрнең сырхауларын үзенә ала, дип ышанганнар. Халык, чыршы тирәли әйлән-бәйлән йөреп, аны яндыра торган булган. Хәзер бу гадәт онытылды инде. Миңа чыршыларны туралган килеш китерделәр. Аларны хәзер кәҗәләремә, сарыкларыма, дуңгызларыма бирәм, – диде әңгәмәдәшем.

Югары Ослан фермеры азык-төлек калдыкларын да кабул итәргә әзер. Әйтик, банан, әфлисун, мандарин кабыгы сарыклар өчен иң тәмле сый икән.

– Кешеләр ризык калдыкларын ташлый бит хәзер, ә коммунистлар чорында, һич югы, һәр подъезд янында аның өчен махсус чиләкләр куела иде. Мин бит әле венгер мангалицасы дигән токымлы йонлач дуңгызлар тота башладым. Алар заманында безнең җирлектә дә яшәгән. 922 елда Болгарга килгән гарәп илчесе Ибн Фадлан бөтен кешенең йонлач дуңгыз асраганын язып калдырган. Мин шуларны кире кайтардым, – дип сөйләде Морат әфәнде.

**Линар ЗАКИРОВ** әзерләде.

# МАЙ КАП!

**Сыер мае ашамыйм, анда холестерин күп, симертә диючеләргә: «Аз кап, май кап», – дип җавап бирәләр. Кеше майдан түгел, аны күп ашаудан симерергә мөмкин. Сыйфатлы майда кеше организмына кирәкле 150 төрдәге май кислоталары бар, шуларның 20 төрдәгесенә алмаш юк. Сөттәге май кальцийны үзләштерергә дә булыша, тиешле күләмдә кулланганда, хәтта холестеринны киметергә дә ярдәм итә. Сыер мае ашаганчы, үсемлек майларына өстенлек бирергә кирәк, диючеләр дә ялгышалар. Кайбер үсемлек майларыннан хасил булган май кислоталары организмның кальцийны үзләштерүенә комачаулый һәм, киресенчә, кан тамырларына утыра.**



*Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА,*
Азнакай






Акыллы һәм матур булу өчен дә сыер мае ашарга кирәк. Май ярдәмендә баш мие күзәнәкләренең яңаруы башкарылса, аның составындагы A, E, D, K витаминнары чәчне үстерә һәм бит тиресен тигез, матур итә.

Югарыда язылганнарның барысына да ирешергә була, әгәр дә аз кап, май кап дигәндә капканың чыннан да сыйфатлы, экологик чиста сыер мае булса. Соңгы елларда май дип ниләр генә сатмыйлар. Казан тирәсендә кайсы гына сату ноктасына барсаң да, Арча, Балтач мае дип сатсалар, Татарстанның икенче бер кырына китсәң, һәр нокта да Азнакай мае гына сатыла икән диярсең. Бу очракта сатучылар, халыкның кайсы җитештерүчегә өстенлек биргәненнән чыгып, үзләрен тәкъдим итәләр.

Азнакай май заводы – «Вамин» җәмгыяте банкротлыкка чыкканда, бөтенләй үзгә статуста кала алган заводларның берсе. Аларны «Просто молоко» үзенеке итәргә теләмәгән. Азнакай район башлыгы Марсель Шәйдуллин, җаваплылыкны үз өстенә алып, заводны саклап калган.

– Районда башка җитәкче булса, безнең язмыш нинди булыр иде микән, тәгәл генә әйтеп тә булмый. Марсель Шәйдуллинның тәвәккәллеге, һәр эшне аңлап, төбенә төшеп карар кабул итә белүе заводны саклап калды, анда эшләүче 140 кеше һәм аларның гаиләләре өчен дә бу бик мөһим карар. Заводны туктатсак, бер дигән җиһазлар да, бина үзе дә таралып юкка чыгар иде. Эшләмәгәндә ел әйләнә аны җылытып торып булмый, ә инде температура режимы сакланмый икән, бу приборларның сафтан чыгуына китерә. Кайбер районнарда без моның ачык мисалын күрдек, – ди Азнакай май заводының баш инженеры Альянус Мөхәммәтшин.

Азнакай май заводы республикада югары сыйфатлы ризык җитештерүче буларак билгеле.

–Үзебезнең заводта җитештергән майны да, сырны да дистәләгән ризыклар арасыннан аерып ала алам. Моның өчен тәмләп карау да мәҗбүри түгел, күп вакыт карау да җитә. Әлбәттә, гади сатып алучы өчен бу катлаулырак. Күпләр майны, катырып диярлек, суыткычның иң салкын бүлегендә саклыйлар. Ашарга дигән май плюс 17 градуста торырга тиеш. Ашарга бирәр сәгать кала, майны өстәлгә алып кую кирәк. Шул вакытта гына майның чын тәмен тоеп була. Иң тәмле май, әлбәттә, 17 сәгать мае, – ди баш инженер.

Минем гаҗәпләнүемне күреп, дәвам итә.

– 17 сәгать себеркесе, 17 сәгать мае дигән сүзләр ишеткәнегез юкмыни? Сүз көн озынлыгы турында бара. Җәйнең бу чорында җыелган себерке дә яхшы була, сөт тә икенче төрле тәмле була дип исәпли халык. Көн озынлыгы арткан саен, сөтнең майлылыгы да арта.

Альянус Мөхәммәтшин – Татарстан Республикасы Азык индустриясенең атказанган хезмәткәре. Аның бу өлкәгә килеп керүе очраклы гына булган. Машина йөртү таныклыгын югалтып, юлга чыга алмаган, шул көнне заводта сепаратор ватыла. Төзәтүчеләрне карап-карап торган да эшкә үзе тотынган. Шуннан укырга да кергән, үсешнең бөтен баскычларын да үткән.

– Сатып алучылар безнең ризыкка югары бәя бирә, шуңа күрә Азнакай мае дип алдап сату очраклары да бик күп. Кибет киштәсенә куелып сатылган ризык ул һәрвакыт тере акча. Бүгенге көндә 22 төрдәге товар җитештереп сатабыз. Май, сыр, сөт, каймак, төрле майлылыктагы кефир, катык... Хәзер халык үз сәламәтлегенә игътибарлырак дип уйлыйм. Тагын бер мөһим нәрсә: сөт ризыгының әчүеннән түгел, әчемәвеннән куркырга кирәк.

### Сүз уңаеннан

✓ Май составында булган А витамины ашказанындагы һәм уникеилле эчәктәге яраларның тизрәк төзәлүенә китерә. Грипп белән авырмас өчен һәм иммунитет кимегән очракта, көненә 60-70 грамм сыер мае ашарга кирәк. Организмның майны үзләштерүе 97-98 процентка җитә.

✓ Югары температурада май үзенең витаминнарын югалта, шуңа күрә аны ризык пешеп җиткәч салырга кирәк.

# Штрафны ташлама белән түли башладыңмы?

БЕЛЕП ТОР!

**2016 елның җиткәнен машина йөртүчеләр аеруча зарыгып көткәндер. 1 гыйнвардан юл йөрү кагыйдәләрен бозган өчен 50 процент ташлама каралган, әмма барысы өчен дә түгел.**

*Линар ЗАКИРОВ*

Ташламага ия булу өчен, төп шарт – штрафны 20 көн эчендә түләү. Исәп квитанцияне кулга алган көннән түгел, кагыйдә теркәлгән көннән башлана. «Бәхет хаты» килеп җиткәнче, туйлар узып, туннар тузарга да мөмкин. Шуңа да штрафларны интернеттан карап барыгыз. Әйтик, сезгә 500 сум штраф салынды, ди. Интернетта ул 20 көн эчендә 500 сум дип түгел, 250 сум дип күрсәтеләчәк, ә 21 нче көнне, түләнмәгән очракта, кабат 500гә әйләнә.

Әлеге системаның башка төрле нечкәлекләре дә бар. Алар турында «ШК»га Татарстан буенча юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең пропаганда бүлеге җитәкчесе урынбасары Хәйдәр Җиһаншин сөйләде.

– Штраф өчен түләүне кабул итә торган банк дәүләт һәм муниципаль түләүләр системасына тоташкан булырга тиеш. Штрафны түләгәндә квитанциядәге уникаль идентификацион номерны (УИН) дөрес күрсәтергә кирәк. Дөрес күрсәтмәсәгез, штраф gibdd.ru, gibdd.tatarstan.ru сайтларында түләнмәгән булып кала.

Кайбер банклар дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр системасына тоташмаган. Әйтик, анда барып штрафны түлисез, квитанцияне кулга аласыз, акча дәүләт счетына күчә, ләкин барлык мәгълүмат базаларында ул түләнмәгән булып күрсәтелә. Инспектор, машина йөртүчене туктаткач, штрафның түләнмәгәнен күрә. Бу очракта йөртүче квитанцияне үзе белән йөртергә тиеш була. Шулай эшләнелсә, инспектор шоферны җибәрә. Әмма квитанциягә карап, инспектор штрафның түләнелгәнен базага кертә алмый, шуңа да машина йөртүчегә аны һәрвакыт үзе белән йөртергә туры киләчәк. Исегезгә төшерәм, штрафны вакытында түләмәгән өчен 15 тәүлеккә кадәр кулга алу яки штрафны икеләтә күләмдә түләү каралган.

Шулай итеп, банкка кергәч, беренче эш итеп аның дәүләт һәм муниципаль түләүләр системасы белән элемтә булдыруын сорашырга кирәк. Ә иң әйбәте – gibdd.tatarstan.ru сайты аша түләргә, анда шәхси кабинет та булдырырга мөмкин. Комиссия алынса да, акчаның тиешле урынга барып җитүенә тулысынча ышана аласың, – дип аңлатты Хәйдәр Җиһаншин.

**НИНДИ КАГЫЙДӘ БОЗУЛАРГА ТАШЛАМА КАРАЛМАГАН?**

– алкоголь, наркотик матдәләр белән бәйле булган барлык кагыйдә бозулар;

– медицина тикшерүе узудан баш тартканда;

– тизлекне 40 км/сәгатькә икенче һәм аннан да күбрәк тапкыр арттырганда;

– светофорның кызыл утына икенче һәм аннан да күбрәк тапкыр чыкканда;

– каршы як полосага чыкканда;

– тиешенчә теркәлмәгән машина белән икенче һәм аннан да күбрәк тапкыр идарә иткәндә;

– юл һәлакәтенә эләгеп, кеше сәламәтлегенә зыян салынганда.

# Җырла, җырла, дип әйтәсез... Сезгә нинди ГИМН кирәк?

**Быелдан Биектау халкы ике генә түгел, ә өч гимн башкара башлаячак. Чынлыкта аның музыкасы бар, ә сүзләре юк, шуңа да җирле җитәкчелек конкурс игълан иткән. Татарстан гимны да шундый ук язмышка дучар ителгән иде бит: музыкасы 1993 елда расланса да, сүзләре рәсми рәвештә 20 елдан соң гына, 2013 елда барлыкка килде.**



Илдар Мөхәммәтҗанов фотоархивыннан

Дәүләт Советында Татарстан гимны яңгырый.



Линар ЗАКИРОВ

## ГИМН ЯЗУЧЫГА НИЧӘ СУМ БИРЕЛӘ?

Конкурс шартлары белән тәфсилләбрәк танышу өчен, Биектау районы башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ринат Сабирҗанов белән элемтәгә кердек. Аның сөйләвенчә, гимн музыкасы Биектау районы Дөбъяз авылында туган шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанның «Биектау» шигыренә язылган. Ләкин җирле депутатлар, гимн сүзләре бер генә түгел, ике дәүләт телендә булырга тиеш, дип, шигырьне үткәрмәгән, ә музыканы кабул иткәннәр.



– Кайбер мәктәпләрдә Рафис Корбан шигыре район гимны буларак язып куелган. Болай итмәгез, сүзләре рәсми рәвештә юк бит әле, дип мәгариф хезмәткәрләренә матур гына аңлаттык. Кайбер район гимнарының көен генә ишеткәнем бар, күпчелегендә анысы да юк әле. Татарстанныкына да ничә еллар буена сүзләр таба алмадык. Гимн балаларга тәрбия чарасы буларак та әһәмиятле. Безнең районга беркетелгән Татарстан Дәүләт Советының элеккеге депутаты Азат Зыятдинов: «Гимн сүзләре белән ашыкмагыз әле, бик җитди әйбер бит ул», – дип әйтә иде, – дип сөйләде Ринат Сабирҗанов.

Конкурс нигезләмәсендә язылганча, гимн тексты ике куплет һәм кушымтадан торырга тиеш. Анда Биектау тарихын, истәлекле урыннарын, географик үзенчәлекләрен, мәдәни традицияләрен, җирле халыкның холык-фигылен чагылдыру шарты куелган. Эшләр 15 февральгә кадәр кабул ителә. 28енә кадәр җиңүче ачыкланырга, ә беренче майга кадәр гимн инде яздырылырга да тиеш.

Конкурс комиссиясе иң уңышлы ике әсәрне сайлап, район Советына тәкъдим итәчәк. Соңгы сүзне депутатлар әйтә. Район халкы хөкеменә иҗат җимешен Сабан туенда тәкъдим итәргә җыеналар. Ә иң кызыгы... җиңүчегә 30 мең сум бирелә.

– 30 мең сум әз түгелме соң? –дип сорыйм Ринат Сабирҗановтан.

– Көен дә 30 меңгә яздырттык. Сезгә, бәлки, әзрәктер, безгә күбрәктер, – диде ул.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан белән дә элемтәгә кереп, конкурста катнашырга җыенамы, юкмы – шул хакта сорадык. Җыенмый икән.

## МАМАДЫШТА ГИМННЫ КЕМ САЙЛАГАН?

Ә менә Мамадыш гимны бер дә «гарип» түгел: сүзләре дә, көе дә бар. Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Алена Смирнова «ШК»га сөйләгәнчә, конкурс бер ел дәвам итеп, районның җырлы-моңлы «визит карточкасы» былтыр район сессиясендә кабул ителгән. Җюри хөкеменә утызлап эш килеп ирешкән. Мамадыш Мәскәү өлкәсенә Сабан туйлары оештырырга ярдәм итә, шундагы иҗатчылар да үзләренең мөмкинлекләрен сынап карыйсы иткән.

– Конкурс комиссиясенә музыка, әдәбият, шигърият белгечләре, журналистлар, җәмәгатьчелек вәкилләре кертелде. Комиссияне җитәкләгән район башлыгы һәр вариантны дикъкать белән тыңлады. Матбугат чараларында конкурсны яхтыртып бардык, сайтта тавыш бирү оештырдык. Финалга узган өч гимнны, сүзләрен русчага, татарчага тәрҗемә итеп, көйләре белән бергә депутатларга тыңлаттык. Сайлап алынганына да үзгәрешләр кертергә туры килде. Гимнны оркестр белән яздырып, беренче тапкыр район Сабан туенда яңгыраттык, – диде район түрәсе.



Җыр сүзләрен – Рафаэль Газизов, музыкасын Александр Штенгауэр язган, икесе дә Мамадыштан чыккан, аларга акчалата премия тапшырылган, әмма әңгәмәдәшем аның күләмен исендә калдырмаган.

– Алена Петровна, Мамадыш гимнын яттан беләсезме?

– Әлегә белмим, тик әлегә... Ятларга, дигән максат куям.

## АЗНАКАЙ БАШЛЫГЫ ТЕЛЕФОНЫНДА НИНДИ ҖЫР?

Азнакай турында кырыклап җыр язылса да, берсенең дә гимн дәрәҗәсенә үсеп җиткәне юк. «Квартет» ансамбленең Азнакай турында башкарган җыры җирле халык кына түгел, җитәкчеләр арасында да бик популяр икән, ул хәтта район башлыгы Марсель Шәйдуллинның кесә телефонынnan яңгырап тора. Район Советы аппарат җитәкчесе Айдар Хәлиуллин бу мәгълүматны безгә раслады.

– Ә сезнең телефонда нинди җыр яңгырый? – дип сорадым үзеннән.

– Виброзвонок тора. Киңәшмәләрдә күп катнашканга, телефон тавышын кабызырга да куркам, – дип көлде ул.

Айдар Хәлиуллин әйтүенчә, 2006 елда муниципалитетлар оешканнан соң, район әләме белән гербын конкурс үткәреп раслагач, гимн да кирәк, дип сүз куерткаңнар. Татарстан гимны бар бит, шул җиткән, дип, ниятләреннән кире кайтканнар.

– Өлгереп җитмәгәнбездер, күрәсең. Азнакай турындагы җырлар шул кадәр матур, һәрберсе гимн булырлык. Конкурс игълан итеп, халык фикеренә таянып, үз гимныбызны булдырырга кирәк инде, җитмәсә, сез дә безгә этәргеч бирдегез. Бүтән районнардан калышып булмас. Гимнга дөрес караш тәрбияләүне балалардан башларга кирәк. Чит илләрдә мәктәпләрдә аны һәр иртә уйнаталар, диләр. Ул яңгыраганда, басарга кирәк. Кайвакыт Азнакай Сабан туена чит ил кунаклары килә. Гимн уйный башласа, халыкның яртысы баса, яртысы утырып тора, бик оят булып китә, – диде район Советы аппараты җитәкчесе.



## «ЯЗУЧЫНЫҢ ЭШЕ ҖИҢЕЛ, ДИП УЙЛЫЙЛАР»

Шагыйрә Фәйрүзә Мөслимованың Татарстандагы бер районның да гимнын ишеткәне юк. Әйтүенчә, туган ягы Актаныш турында бик күп җырлар язылган, ләкин берсе дә гимн буларак рәсмиләштерелмәгән. Фәйрүзә ханым сүзләренчә, гимн рәсми дә, җитди дә, лирик та булырга тиеш. Әмма гимн тиклем гимн язган кешегә 30 мең сум түләү аз, ди.



– Язучының эше җиңел, дип уйлыйлар. Җырчыларның концертларына акча түләп керергә кирәк, ә язучылар очрашуларда бушлай чыгыш ясый. Җырчылар шул язучылар иҗат иткән җырларны башкарып йөри бит, авторны, теләсәләр, әйтәләр, теләмәсәләр, юк. Төп иҗатчылар күләгәдә кала. Районның 100 мең сум гына бирерлек мөмкинлеге булырга тиеш, – диде шагыйрә.

**«Шәһри Казан»ның электрон тартмасына «Биектау гимнын нинди адреска җибәрергә икән?» дигән сорау килеп төште. Конкурска эшләр шушы адрес буенча кабул ителә: 422701, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Кооператив урамы, 5 нче йорт. 203 нче бүлмә. Биектау районы башлыгы урынбасарына.**

# Әбиләр дә, бәбиләр дә тау шуа



Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Ахыры. Башы 1 нче биттә.

**Алисә САБИРОВА**

Текә таудан югары тизлектә төшүче бер төркем чаңгычы янибыздан «чыжылдап» кына узып китә. Берсенең дә, ахырдан килеп, оятка каласы килми шул.

Эзмә урта мәктәбенең физик тәрбия укытучысы Азат Галиев балаларны шулай көн дәвамында чаңгы шуу серләренә өйрәтә. Ул үзе дә спорт мастеры, егерме елга якын көрәш белән профессиональ шөгыльләнгән кеше. Студент елларында чаңгы шуу белән җенләнә, хәзер укучыларына гына түгел, авыл халкында да кышкы спортка мәхәббәт тәрбияли.

– Менә шулай инде биш ел рәттән балаларны чаңгыга бастырам. Быел кар аз булу сәбәпле, тау шууның да үз кыенлыклары килеп чыкты. Хәзер тау башына «ылыслап» менәсе юк. Тауга кадәр укучыларны «Буран» матае белән алып менгән вакытлар да булды. Яңа технологияләр монда да барып җитте, тауга мену өчен махсус тросс тарттырылган. Бер минут дигәндә, рәхәтләнеп утырып, тау өстенә менәсең, – ди Азат Галиев.

Эзмә мәктәбендә спортның слалом дип аталган төре белән хәзер 30га якын бала шөгыльләнә.

– Слалом – төрле каршылыклар тудырылган текә тау маршруты буенча шуу. Ул күп көч сорый, махсус аяк киемнәренең авырлыгы гына 10 килограммга җитә. Ә чаңгының бер пары 30 мең тора, – ди физик тәрбия укытучысы.

Киләчәктә Эзмә авылы халкы Калатауда тау шуу комплексы булдырырга хыяллана. Бу инде 2016 елның планына кертелгән. Тау чаңгы шуу трассасыннан тыш кафе, кунакханәләр белән уратып алынган туристик базага әйләнәчәк. Әлегә ул курортка әйләнмәсә дә, аның иртә-кич тынып торганы юк.

– Элек алай түгел иде, хәзер бөтен кешене уятып бетердем инде. Тау башында кеше бик күп, гаиләләре белән чыгучылар да бар. Пенсионерлар бик актив. 60-70 яшьлекләр дә чаңгыга баса. Буран чыкса, авылдашлар, чаңгы шуып булырмы икән, дип борчыла башлый, – ди Азат Галиев.

Чаңгы трассасын кар каплаган саен, «Буран» матае белән, укытучы аны кабат үзе ясый. Бер юл салыр өчен, тауны «Буран» белән биш тапкыр әйләнергә кирәк икән.

Алда әйтелгәнчә, Калатау – чаңгы шуу буенча өч республика ярышлары призерларын һәм чемпионын әзерләгән җир. Әлеге спорт белән профессиональ шөгыльләнүчеләр чаңгыларын җәен дә салмый. Тауның буеннан-буена асфальт трасса салынган. Яшьләр биредә шулай ук велоспорт һәм җиңел атлетика белән дә шөгыльләнә.

## БӘХИЛЛӘШҮ

### ҮЗӘКЛӘРНЕ ӨЗЕП КИТТЕҢ

**Татар җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде: Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Наил Шәйхетдинов арабыздан китеп барды...**



Тинчурин исемендәге театрны Наил Шәйхетдиновтан башка күз алдына да китереп булмый. Аның уйнаган һәр роле тормышчан, җан җылысы белән иҗат ителгән иде. Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» спектаклендә – Хуҗа, Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә»сендә – Юныс, Хәй Вахитның «Кияүләр»ендә – Җамали, Илдар Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә»сендә – Хәмзин. Артистның «Гайфи бабай, өйлән давай!» спектаклендә уйный башлавына март аенда 20 ел тулса, үзенә 75 яшь туларга тиеш иде. 50 ел буе ул сәхнәдә 200дән артык образга җан өргән. Авырып йөргәненә карамастан, узган елның 16 декабренә кадәр сәхнәдән аерылмады ул. Шул кичне «Йосыф-Зөләйха»ны соңгы мәртәбә уйнармын дип уйламагандыр... Әмма декабрьнең соңгы көннәрендә кичергән операция өметсез булып чыга.

Наил Шәйхетдиновны соңгы юлга озатканда хезмәттәшләре, дуслары аның талантлы, кешелекле, гадел булуын әйттеләр.

**Исламия МӘХМҮТОВА:**

«Үзәкләрне өзеп китәсең, Наил. Әле декабрьдә генә Гайфи бабайны дөбердәтеп уйнадың. Наил сәхнәдә минем сөйгәнем дә, ирем дә, картым да, дустым да булды. Искиткеч партнер иде ул. 50 ел буе татар халкының яраткан артисты булдың син».

**Хәлим ҖӘЛӘЛОВ:**

«Бүген театр зур югалтуга дучар. Укуын тәмамлау белән, Наил Шәйхетдинов газиз халкына хезмәт итте. Без аның белән бергә укыдык. Аңа тыйнаклылык, сабырлык, әдәплелек сыйфатлары тупланган иде. Алар хатыны Миңлегөл ханым белән кызлары – талантлы артист Миләүшә Шәйхетдиновага үстерделәр. Наил безнең арадан иманлы булып китте».

**Айдар ХАФИЗОВ:**

«Безгә Наил белән бер үк спектакльләрдә уйнау насыйп булды. Халык аны авылларда туганнарын көткәндәй көтеп ала торган иде. Хаҗ кылырга да без бергә бардык. Совет чорында да ул намазын ташламады».

**Нуриәхмәт САФИН:**

«Наил тырыш, эшчән, намуслы иптәш булды. Без аның белән партнерлар булып уйнадык. Ул безнең сыйфат билгесе дә иде. Син яшьләргә терәк булдың. Аларга тормышта ялгыш адым ясамаска киңәшләрең белән ярдәм иттең».

Наил Шәйхетдинов сәхнәдә тудырган рольләр тиз генә тамашачы күз алдыннан китмәс, күңелләрдә озак сакланыр.

**Мәрхүмнең җәсаде Самосырово бистәсендәге татар зиратында җирләнде.**

### ВӘСИЛӘ ФӘТТАХОВАНЫ ЮГАЛТТЫК

**Башкортстаннан тагын бер кайгылы хәбәр килеп ирешә. Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган артисты Вәсилә Фәттахованы соңгы юлга озаттылар.**



Башкортстанның Белорецк шәһәрендә туып, Учалы музыка училищесын тәмамлаган кыз популяр җырчы Айдар Галимов төркемендә эшли башлый. Эстрадага ул үзенең кабатланмас моңы белән килеп керде. Бигрәк тә «Туган як» җыры белән татар, башкорт тамашачысының күңелен яулады. Ул җырга хәтта руслар да кушылып җырлый иде. Вәсиләнең «Туган як», «Мәхәббәт кыллары» альбомнары дөнья күрде. Ул «Бәллүр сандугач», «Татар җыры» конкурсларында катнашты.

Вәсилә Фәттахова икенче баласы – кызын тапканнан соң, савыга алмыйча, төрле хастаханәләрдә операцияләр кичерә. Әмма табиблар 36 яшьлек артистның гомерен саклап кала алмыйлар.

Без дә мәрхүмәнең туганнарының, дусларының тирән кайгысын уртаклашабыз.

# Резеда Шәрәфиева:
# «Көнчелек турында уйлап, вакыт әрәм иткәнем юк»



**Резеда Шәрәфиева 50 яшен тутырып, шул хакта татар эстрадасына якын халыкка концерт куеп хәбәр итте. Концертны караган тамашачыларның комментарийларындагыча «18 яшьлек зифа кызлар кебек, битендә бер генә дә җыерчыгы булмаган» артистка яшен нигә яшереп торырга ди. Резеда белән бик күптәннән таныш буларак, аның картая белмәүче җырчы икәнлеген мин дә раслыйм. Шулай!**

**– Язмышыңны җыр белән бәйләвең бер очраклылык кебек кабул ителсә дә, җырлый башлавына инде 20 елдан артып киткән. Рәссамлыктан «кыек юлга» – җырчылыкка күчүең шактый капыл һәм уңышлы булды. Үзең дә шул фикердәме?**

– Бераз буталып, син әйткән «кыек юл»га кереп китүемә мин бик шатмын. Үземнең тамашачым бар, рәхәтләнеп, кирәклегемне, тыңлаучыларымның үземне яратуларын тоеп яшим, эшлим. Шулай булмаса, җырлап торуның кирәге дә булмас иде.

**– Үзеңне нинди җырчы дип бәялисең?**

– Бик тыйнак инде мин.

**– Нәрсәдә чагыла ул тыйнаклыгың?**

– Бөтен нәрсәдә дә. Сәхнә кешесе бераз әрсезрәк булса әйбәтрәк бит инде ул.

**– Минемчә, син тыйнаклыгың аркасында әллә ни каза күрми генә, уңышлы гына эшлисең, хәтта тормышта барысы да майлаган кебек бара дияр идем. Һәрхәлдә, читтән шулай күренә. Эстрада артистлары арасында дусларың күпме?**

– Аллага шөкер, эстрадада да дусларым күп, гадәти тормышта да җитәрлек. Рөстәм Закиров, Алсу Әбелханова белән бик дус без, гомумән, татар эстрадасындагы барлык артистны да үземнең дустым итеп хис итәм, яшен дә, картын да дигәндәй. Бер-береңә булышсаң, хөрмәтле мөгамәләдә булсаң, әйбәт бит инде ул. Көнләшү, үчләшү дигән нәрсә юк миндә. Кемдер сиңа карағанда уңышлырак икән, нигә аннан көнләшергә, бары үзеңә дә ныграк тырышырга гына кирәк.

**– Ә синнән көнләшүчеләр бармы соң?**

– Каян белим, бәлки бардыр да инде. Дөресе – шикләрем бар, ләкин ул хакта уйлап, вакыт әрәм иткәнем юк. Барысына да елмаеп, йомшак сөйләшеп тик йөрим.

**– Түгәрәк туган көн уңаеннан зур табын корырсың инде. Сине мин бик мул куллы дип беләм, чынлап та шулаймы?**

– Кирәгеннән артык мул куллы мин, Аллага шөкер. Ничек бирсәң – шулай аласың бит ул.

**– Сез гаиләдә ничә бала?**

– Без дүртәү, мин иң олысы.

**– Әти-әниең сине башка туганнарыңнан артыграк яраттылар дип әйтә аласыңмы?**

– Беренче бала ныграк яраталадыр инде ул. Мине бабам бик яраткан. Әни әйтә, бабаң сине «алтын тәслем» дип кенә йөртә иде, ди. Әтинең әтисе булган инде ул. Мине кулына алган саен: «Күрерсез, минем кызым бер гөрләтер әле», – дия торган булган. Әни: «Әбиең: «Нәрсә сөйлисең соң син, нәрсәне гөрләтер?» – дип ачуланып та куя иде үзен», – ди. Кем уйлаган, бабамның сүзе рас килеп, сәхнәгә менәрмен, мине меңләгән тамашачылар тыңлар дип. Әле мин үзем дә һаман да ышанып бетмим, сәхнәдәге Резеда ул мин түгелдер сыман.

**– Шәхси тормышың да җайланды кебек.**

– Аллага шөкер. Бүгенге көнемдәге кебек халәттә, картаймыйча, туган-тумачаларым, якыннарым, дусларым исән-сау булып, бәла-казаларга тарымыйча, тыныч кына, матур гына бик озак яшәргә иде әле.

**– Кызың да зур инде.**

– Кызыма быел – 10 яшь. Әнигә – 70, миңа – 50. Бездә быел юбилейлар елы. Кызым Зөләйха поляк-инглиз телләрен тирәнтен өйрәнүче мәктәптә укый. Махсус телләр өйрәнсен дип сайламаган идек, өйгә якын булганга сайланды. Хәзер үзебез бик канәгатьбез, мәктәбебез әйбәт.

**– Ничә яшькә кадәр җырлармын дип уйлыйсың?**

– Бигрәк куркыныч сорау бирәсең, 50 тулып туктамам инде.

**– Тукта димим бит, ничә яшьтә туктарсың икән, дим. 90да йә 100дә дип җавап бирә аласың.**

– Юк инде, картаеп, ямьсезләнеп беткәч, сәхнәгә чыкмау хәерлерәк булыр.

**– Бу әле синең 50 яшьлек «балалыгың» биргән җавап. Күпләрнең 80не узгач икенче сулышлары ачыла, минем хәтердә андый очраклар һәм ишеткән сүзләр бар.**

– Бирсен Ходай.

**– Хәзер хатын-кызларның кул эшләре белән мавыгуы кабат «мода»га керде. Син рәссам, дизайнер, андый берәр шөгылең бармы?**

– Аңа вакыт юк әле. Башланган, ләкин тәмамланмаган картиналарым бар, Зөләйха да ясаштыргалый. Без гел юлда бит. Гастрольдә булмаганда, авылга кайтабыз. Авыл Казаннан ерак. Юл да хәлне ала.

**– Кызың авылны яратамы соң?**

– Ул кечкенә вакытта гел авылда булдык, бик еш кайта идек. Быел әбисенә әйтә: «Әби, мин аңладым, Казанда яшәү рәхәтрәк икән», – ди. Хәзер Зөләйха зур кыз бит инде, авылга кайтып курчак уйнап утырасы түгел, эш эшлисе, бәрәңге чүбе дә утыйсы бар. Аннан, барлык оча торган бөҗәкләрдән курка ул. Чебеннән, бал кортыннан коты оча, берничек тә шул куркуыннан биздереп булмый. Бөҗәксез авыл юк бит ул. Үскән саен, авылга сирәгрәк кайтырга дигән сәбәпләрне табып кына тора.

**– Мәхәббәт бармы ул?**

– Ничек булмасын, бар!

**– Әгәр сиңа дуслыкта, мәхәббәттә хыянәт итсәләр, син үзеңне ничек тотасың?**

– Ул кешеләр белән исәнләшәм, аралашам, ләкин бер җитди эш тә йөртмим.

**– Кемнедер яклап, үзеңнең уңайсыз хәлдә калганың булдымы?**

– Минем ул яктан хәйләм бар – башкаларны үземә зыян салмый гына яклый беләм, кызып киткән мәлдә дә каты сүз әйтми кала алам.

**– Алтын балык тотып, аңа өч теләк әйтә алсаң...**

– Якыннарыма исәнлек, сәхнәдә озын-озак иҗат итү, дөньялар, илләр-җирләр имин булсын.

**– Кызың буй җиткәч, башка милләт егетенә гашыйк булса, моны ничек кичерерсең икән?**

– Мин кызыма бәхет телим, әлбәттә. Шулай да, андый очракта борчылыр идем. Без, татар артистлары, бик аралашып яшибез, күбебезнең балаларыбыз яшьтәшләр. Малайлар бар, кызлар, аларны аралаштырырга, төрле бәйрәмнәрне ешрак оештырырга тырышабыз. Үзебезчә шулай «димләштерәбез» инде. Зәмирә Рәҗәпова безнең кызыбызны шаярып «килен» дип йөри инде. Мин үз чиратымда кызымны бөтен өй эшләренә, чисталыкка, пөхтәлеккә өйрәтәм. Анасы эшкә өйрәтмәгән, дип сукмасеннәр дим. Шулай яшәп ятабыз менә. Сәхнә дә, өй дә, бала да – барысы да гармониядә.

**Зимфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА.**

## АЙГӨЛ НӘБИУЛЛИНА – ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН МӘДӘНИЯТ ХЕЗМӘТКӘРЕ

«Мәйдан» каналының баш мөхәррире Айгөл Нәбиулла тормышындагы күңелле яңалыкны белми дә калганбыз. Баксаң, ул хәзер «Атказанган мәдәният хезмәткәре» исемен йөртә икән. Чын күңелдән котлыйбыз!



– Май аенда приказ чыккан иде, декабрь ахырында медален дә тапшырдылар, – диде Айгөл. – Исем алдым дип, тормыш әллә ни үзгәрмәде. Эшлибез, тырышабыз. Гаиләгә килгәндә, бар да тәртиптә. Җәйдән бирле яңа йортыбызда яшәп ятыш. Улыбыз Альфред – өченче курс студенты, сессиясен ябып, каникулда ял итә. Кызыбыз Эминә беренче сыйныфта белем ала, нәфис гимнастика белән шөгыльләнә.

## ИЛШАТ ХӘМӘДИЕВ «КОЙРЫК»ЛАРЫН ТӨЗӘТЕП ЙӨРИ

– Мәскәү дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтының Чаллы филиалында укыйм. Күбрәк



ял ителгән, ахрысы, сессияне ябарга маташып, «койрык»ларымны төзәтергә йөрим. Тагын биш «койрык» бар әле. Укытучылар да булышырга атлыгып тормый. 27 февральдә эти белән Филармониядә уртак концерт куябыз. 23 мартта Чаллыда үземнең «сольнигым»ны тәкъдим итәргә исәп.

# Үз тиңеңне табу өчен мәхәббәт кенә түгел... инструктор да кирәк

**Бушлай игъланнар сайтында кызык кына бер игъланга күзем төште – «Танышулар буенча инструктор». Игълан астында күрсәтелгән номерны җыйдым. Психолог Фаяз Төхбәтуллин татар егете булып чыкты.**
**Фаязның әйтүенчә, аңа күбрәк хатын-кызлар килә. Алар барысы да үз тиңнәрен табып, уңышлы гына кияүгә чыгарга тели.**


Фаяз Төхбәтуллин.
Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Диләрә САДЫЙКОВА

### «ҮЗЕГЕЗНЕ ЯРАТЫГЫЗ, КЫЗЛАР»

– Мин аларның һәрберсе белән аерым эшлим. Гадәттә, күп кенә кызларның проблемалары үзендә була. Мин дөрес сөйләшмимдер, минем егетләргә кыяфәтем ошамыйдыр, диләр. Эш анда түгел, ә күңел халәтендә. Кемдер җавапсыз мәхәббәттән курка, кемдер ташлап китәрләр дип борчыла, өченчеләренең әтисе яки башка ир-ат туганы белән мөнәсәбәтләрендә проблема булган – менә шушы комплекслар комачаулый аларга. Мин, психолог буларак, шушы проблемалар белән эшлим. Әгәр дә инде кеше үзе белән гармониядә яши, аның бернинди дә комплекслары юк икән, аларга танышу, үз-үзеңне егетләр янында тоту кагыйдәләрен өйрәтү дә җитә.

**– Хатын-кыз журналларында, гадәттә, егетләр белән танышу өчен ирләр күп була торган урыннарга, әйтик, фитнес клубларга, төзелеш материаллары яки кыйммәтле сәгатьләр сатыла торган кибетләргә йөрергә кушалар...**

– Мин үзем дә шундый ук киңәшләр бирәм. Хәзер егетләр үзләре дә урамда танышмыйлар. Элек кенә ул «Нофелет кайда урнашкан?» дигән булып танышып киткәннәр. Күп кенә кызлар эшкә бара да өенә кайтып утыра. Аның башка нәрсәгә вакыты да, энергиясе дә калмый. Алар үз өсләрендә эшләүдән туктыйлар. Берәр кул эше белән шөгыльләнегез, фитнес клубка йөрегез дип киңәш итәм кызларга. Ирләргә ошар өчен генә түгел, үзегез өчен эшләгез моны. Үзегезне яратыгыз, аннары сезне дә яратырлар. Тырнакларыгыз, чәчләрегезне карагыз, матур киемнәр алыгыз. Үзегездән канәгать була башлагач, янығызда кемнең дә булса барлыкка килүен сизми дә калырсыз. Күңелегездә кояш булганда, йөзегез дә яктыра.

### БӘХЕТ ӨЧЕН КӨРӘШ

**– «Самая обаятельная и привлекательная» фильмында Сусанна иптәш кызына «матур булып туma, актив булып ту, ирне үзеңә эзләргә кирәк» ди. Кызлар, беренче булып, үзләре таныша аламы?**

– Әлбәттә. Тик яткан таш астыннан су акмый диләрме әле бездә? «Тәртипле кыз беренче булып танышмый» дигән чикләрдән чыгарга кирәк. Үз бәхетең өчен үзең көрәшәсең.

**– Әгәр дә сиңа берәрсе ошады ди, ничек сүз башларга?**

– Аның өчен бер анык мисалны алырга кирәк. Тренажер залына ирләр күп йөри, алар үз тәннәрен, сәламәтлекләрен карыйлар дигән сүз. Андый егетләргә, әлбәттә, күз төшә. Янына кил дә: «Ничек уйлыйсыз: миңа ничә килограммлы гантель сайларга икән?» – дип сора. Үзең мөлаем гына елмай. Ир-ат ярдәм сораганнарын ярата, шунда ук булыша. Синең шулай яшерен генә танышырга ниятләгәнеңне дә белеп тора ул. Сөйләшеп китәргә җай да чыга.

**– Әгәр дә ул гантельне алып биреп китеп барса?**

– Ул шөгыльләнә торган тренажерлар тирәсендә йөргәләгез, ара-тирә күзенә чалынып торыгыз. Егетләр тышкы кыяфәткә дә игътибар итүчән. Мин тонналап иннек сыларга, кыска шорты кияргә кушмыйм. Әмма егетнең күзе төшәрлек булсын. Танышып булмаса, зарар юк. Алда әйткәнемчә, кеше үз-үзе белән гармониядә яши икән, аның бернинди дә комплекслы булмаса, танышу барып чыкмаганга борчылырга тиеш түгел.

**– Винни Пух сыман бу ситуациягә «бу дөрес бал кортлары түгел, алар дөрес бал ташымыйлар» кебек кенә карарга да оныргамы?**

– Башка чара юк. Егетләрнең үзләре кебек кешене аптыратып-тинтерәтеп бетерергә кирәкми, хатын-кыз үзенең дәрәҗәсен белергә тиеш.

### «ЫШАНЫЧЛЫ ТЕРӘК КИРӘК»

**– Интернет аша танышып аралашу күпкә уңайлы түгелме?**

– Уңайлыдыр да, әмма мин алай танышу ягында түгел. Синең белән кем аралашып утыруын белмисең бит.

**– Ничек уйлыйсыз, үз тиңеңне табу яшь барган саен авырмы?**

– Аны теләсә кайсы яшьтә табып була. Теләгең генә булсын.

**– Яшь барган саен, ирләргә карата таләпләр дә кимидер?**

– Яшьрәк кызлар өчен егетнең статусы мөһим. Яхшы урында эшләсен, яхшы профессия кешесе булсын! Олырак ханымнарда андый таләп юк. Әмма матди яктан тотрыклы булуы мөһим.

**– Гомумән алганда, хатын-кызлар ир-атлардан нәрсә көтә? Алар эзләгән ирләрнең билгеле бер рейтингы бармы?**

– Бар. Алар янында беренче чиратта үзләрен яраткан кеше булу мөһим. Матди яктан тәэмин итәргә сәләтле кеше кирәк. Андый кешедән бала да табасы, балалар да үстерәсе килә. Кыскасы, ышанычлы терәк кирәк.

Әлбәттә, һәр очрак үзенә бер. Сорауларыгыз булса, мин сезнең белән социаль челтәрдә аралашырга әзер.

## Беренче очрашуда үзеңне ничек тотарга?


prokazan.ru

• Тыңлый белергә өйрәнегез, бүлдермәгез. Кызыксынып тыңлаган кыяфәт чыгарыгыз.

• Ир-атлар комплимент әйткәнне дә ярата. Әмма ул урынсыз булырга тиеш түгел. Сәгатегез матур, миңа ошый дип куегыз. Урамда барганда агач башыннан мәчене алып төшеп бирсә дә, мактагыз. Сез кыю икән диегез.

• Аның тормышының якты якларына, үзе белән булган күңелле вакыйгаларга, уңышка ирешкән өлкәгә кагылышлы сораулар бирегез. Ул алар турында рәхәтләнеп сөйләячәк. Өенә кайткач та, энә өстендә утырган кебек булды, бу кыз кирәкмәгән сораулар гына биреп утырды диярлек булмасын. Ул очрашуга эштән соң арып килә. Аның ял итәсе килә. Авыр, катлаулы сораулар биреп, башын катырмагыз. Әгәр дә инде эштәге берәр күңелсез вакыйга турында, әйтик, хуҗасы белән ачуланышканын әйтсә, син дөрес эшләмәгәнсең димәгез. Кәефен төшермәгез. Нәрсә эшләргә кирәклекне өйрәтергә тотынмагыз.

• Үзегез турында гына сөйләп утырмагыз. Менә мин студент чакта беръюлы өч егет белән очраша идемише сүзләр дә сөйләп утырырга кирәкми. Ул аңа кызык булырга мөмкин. Әмма ышанычлы кеше түгел икән дигән фикер дә калдырмагаегыз.

• Шуны да истән чыгармагыз: ресторанга яки башка җиргә кергәндә, ишекне ачканын көтегез. Беренче булып сез ачып кермәгез. Кая утырабыз дисә, син кая телисең, шунда диегез. Бу аңа үзен ир-ат итеп хис итәргә булыша. Кайбер егетләр, сиңа ошарга тырышып, синнән дә сорарга мөмкин. Әмма алар дөрес эшләми. Ул хәл итсен. Син аңа гына иярергә тиеш.

• Кайбер кызлар, бушка бит дигән булып, әллә никадәр әйбергә заказ бирә. Егет күп итеп ашаганын күрсә, бу миңа кыйбатка төшә дип тә уйларга бик мөмкин. Мин моны шаяртып әйтмим, ул чыннан да шулай.

• Ашаган өчен акчаны кем түләргә тиеш, диләр күп вакыт. Әлбәттә, егет кеше. Үзем түлим диергә кирәкми. Югыйсә ул бу минем белән шулай хушлашырга җыена дип тә уйларга мөмкин. Ә инде икегә бүлеп түләргә тәкъдим итсә, түлисез. Бу очракта аның турында саран дигән нәтиҗә чыгарырга ашыкмагыз. Төрле хәлләр була, акчаны күбрәк алырга кирәклеген онытан булырга да мөмкин.

# Зөләйха күзләрен ача

**Гүзәл ЯХИНА**

**Флёра ТАРХАНОВА** тәрҗемәсе

→ Дәвамы. Башы 2015 елның 24 декабрь, 2016 елның 21 гыйнвар санында.

Озак та үтми, каен көчләрәк дерелди һәм чайкала, катырак ыңгыраша башлады. Кәүсәсендә балта чабудан барлыкка килгән яра тавышсыз гына кычкырырга ачылып киткән авызга охшап калган. Мортаза, балтасын ташлап, җилкәсеннән ботак-йомычкаларны кагып төшерде дә Зөләйхага баш какты – ярдәм ит, янәсе. Алар икәүләп җилкәләре белән кытыршы кәүсәгә терәлеп этә башладылар – көчләрәк итеп, тагын да көчләрәк итеп... Каен шартлап сынды, тирә-юньгә яңгыраган саубуллашу ыңгырашуы белән күккә кар тузаны болытын күтәреп, җиргә барып төште. Ир җиңелгән агачка атланып алды да, аннан юан ботакларны чабып төшерергә кереште. Ә хатыны, нечкә ботакларны сындыргалап, коры-сары белән бергә кәрзингә тутыра башлады. Озак эшләделәр. Хәтта бер-беренә сүз дә әйтмичә, шактый озак эшләделәр. Бил сызлый, җилкәләр исә арыганлыктан оеп-оеп китә. Куллар, бияләйләрдә булсалар да, туңалар.

– Мортаза, әйт әле, әниең яшь чакта берничә көнгә урманга барган икән һәм аннан исән-сау килеш кайткан, диләр, дөресме?

Зөләйха шул арада, ял итәсе килеп, аркасын турайтты да, билен бөкте.

– Миңа абыстай сөйләгән иде, ә аңа – әбисе.

Ире янә җавап бирмәде. Кәүсәдән тырпаеп торган кәкре, буынтыклы ботакка балтасын турылап тора иде.

– Мин куркудан үлгән булыр идем, әгәр анда булган булсам. Мөгаен, минем аякларым шундук йөрмәс булыр иде. Җиргә ятып, күзләремне йомып, телем әйләнүдән туктаганчы, берөзлексез дога укыган булыр идем.

Мортаза әлеге ботакка каты итеп китереп чапты һәм ул, сызгырып һәм калтыранып, пружина кебек сикергәләп читкә очты.

– Ни дисәң дә, урманда догалардан файда юк, диләр. Укыйсыңмы-укымыйсыңмы, барыбер һәлак булачаксың... Ничек уйлыйсың, – Зөләйха тавышын бераз киметеп, – җир йөзендә Аллаһы Тәгалә күзе төшмәгән урын бармы?

Мортаза җәелеп китеп селтәндә дә суыкта зеңгелдәп торган агачка балтасын батырды. Бүреген салып атты, кызарып чыккан, эссе бөркелеп торган чәчсез шома башын учы белән сөртеп алды да аяк астына лач итеп төкерде.

Яңадан эшен башлады.

Тиздән кәрзин дә коры-сары белән тулачак – аны күтәреп тә булмас инде, өстерәп кенә барырсың. Каен ботаклардан арынды, берничә кисәккә бүленде. Озын ботаклары, әйбәтләп җыелып, янәшәдәге көртләр өстендә бәйләм-бәйләм ята.

Караңгы төшә башлавын да сизми калдылар. Зөләйха күзләрен күккә күтәреп караса, кояш өзек-өзек тотам болытлар артына кереп качкан. Шул арада көчле җил килеп чыкты, җәяүле буран да сызгыра-сызгыра бөтерелә.

– Әйдә, кайтыйк инде, Мортаза, тагын буран башлана бит.

Ире янә дәшми. Утыннарның калын бәйләмен баулар белән чорнавын дәвам итә. Соңгы бәйләм әзер булугә, буран агачлар арасыннан бүре кебек сузып-сузып һәм явызланып улый башлады.

Мортаза мех бияләе белән бүрәнәләргә төртеп күрсәтте – әүвәл боларны чанага илтеп салабыз. Киселгән дүрт бүрәнәнең һәрберсе Зөләйхадан да озынрак. Мортаза тамагын кырып куйды һәм иң юан бүрәнәнең бер башын җирдән күтәреп алды. Зөләйхага икенче башы калды. Тиз генә күтәрә алмады ул, юан һәм бирчәйгән агачка җайлашып, озак маташты.

– Тиз бул! – дип, түземсезләнеп кычкырды Мортаза. – Хатын!

Ниһаять, булдырды Зөләйха. Бүрәнәне ике кулы белән кочаклап, әле генә киселгән, озын, очлы йомычкалар белән ыржаеп торган агачның алсу-ак йомшагына күкрәге белән сыланып, көчкә күтәреп алды.

Чанага таба киттеләр. Әкрен генә баралар. Куллар калтырый. Ычкындырып җибәрмәсәм генә ярый инде. Ходаем, ярдәм ит, ычкындыра күрмим! Аякка килеп төшсә, гомерлек гарип булып каласың. Эссе булып китте – кайнар тир арка, корсак буйлап ага. Күкрәк астына яшереп бәйләнгән алма кагы үтәли җеби – тозланып бетә инде. Анысы куркыныч түгел, тик бүген үк илтеп бирәсе иде...

Сандугач, ялкау гына тыпырчынып, шул ук урында тора. Быел бүреләр аз, сөбханалла, шуңа күрә Мортаза атын берүзен озаклап калдырырга курыкмый.

Бүрәнәне чанага илтеп салгач, Зөләйха бүрәнә янәшәсенә хәлсезләнеп егылып ятты. Бияләйләрен салып, муеныннан яулыгын чишеп җибәрде. Сулу алып та булмый – авырта, әйтерсең лә авылның бер башыннан икенчесенә кадәр туктаусыз йөгереп үткән.




Мортаза, бер сүз дә әйтмичә, калган бүрәнәләргә таба кире китте. Зөләйха, чанадан шуып төшеп, аның артыннан атлады. Калган бүрәнәләрне дә чанага китереп салдылар. Аннары – юан ботаклар бәйләмнәрен, соңыннан – нечкә ботак бәйләмнәрен.

Утыннарны чанага урнаштырып бетергәндә, урман инде кышкы куе эңгер-меңгергә чумды. Яңа гына киселгән каен төбендә бары тик Зөләйханың кәрзине генә калган иде.

– Чыбык-чабыкны үзең алып килерсең, – диде Мортаза, коры гына, утыннарны ныгытып бәйли башлады.

Җил котыра, алар салган эзләрне күмеп китеп, кар болытларын төрле якка очыра башлады. Зөләйха, бияләйләрен күкрәгенә кысып тоткан килеш, инде күренер-күренмәс сукмактан урман караңгылыгына йөгерде.

Таныш агач төбенә барып җиткәнче, чыбык-чабык тутырылган кәрзинне кар күмеп киткән иде инде. Зөләйха куактан бер ботак сындырып алды, аның белән карга төртә-төртә, шул тирәне әйләнеп чыкты. Әгәр тапмаса, нык эләгәчәк үзенә. Мортаза ачуланыр да тынар, ә менә Убырлы карчык туйгәнчы эт итәчәк; зәһәрен чәчеп, әлеге кәрзинне үзе үлгәнче исенә төшереп кирәген бирәчәк.

Менә ич, табылды бит, Аллага шөкер! Утыра мине көтеп! Зөләйха авыр кәрзинне көрт астыннан көчкә сөйрәп чыгарды. Җиңел сулап куйды. Тизрәк китәргә кирәк. Кай якка китәргә соң әле? Зөләйханы һәм тирә-юньне тирәләп, рәхимсез буран котыра. Зөләйханы урап, чолгап алган ак карның ак агымы һавага бер күтәрелә, бер төшә. Күк, коточкыч зур соры мамык булып, чыршыларның тырпаеп торган очлы башлары арасында эленеп калды. Агачлар караңгылыкка төренде, шәүләләр кебек бер-беренә охшап калды. Сукмак юкка чыкты.

– Мортаза! – дип кычкырып җибәрде Зөләйха, авызына кар тулды. – Мортаза-а-а!

Аңа, җырлап, сызгырып, чәрелдәп, буран гына җавап бирде.

Тән хәлсезләнеп, аяклар йомшарып китте, әйтерсең лә алар да кардан ясалган. Зөләйха, бер кулы белән кәрзинне, икенче кулы белән толпып якасын тотып, җилгә аркасын куеп, агач төбенә килеп утырды. Моннан китәргә ярамый – адашуы ихтимал. Шул урында көтү яхшырак. Мортаза аны урманда ташлап калдырмасмы? Убырлы әй шатланыр иде... Ходаем, күпме көч куеп таккан алма кагы нишли инде? Бер дә юкка тырышты булып чыгамы?..

–Мортаза-а-а!

Кар болытыннан колакчын бүрек кигән зур кара фигура килеп чыкты. Хатынының җиңеннән ныклап эләктереп, Мортаза аны буран аша үз артыннан алып китте.

Чанага утырырга рөхсәт итмәде – утын күп, атның тартырга көче җитмәячәк. Җәяүләп киттеләр: Мортаза Сандугачны йөгәненнән тотып – алдан, ә Зөләйха, аякларын көчкә атлатып, арба артына тотынып, эзенә басып бара. Киез итекләренә кар тулды. Салып кагарга көч юк. Әлегә атлап өлгерергә кирәк – адымнарын дөрес ясарга: әле уң аяк, әле сул аяк, әле уң аяк, әле сул аяк... Йә инде, Зөләйха, җебегән тавык, атла, атла әйдә. Үзең беләсең: чанадан аерылып артта калсаң – бетәчәксең. Мортаза сизми дә калачак. Урманда катып үләчәксең.

Ни дисәң дә, нинди яхшы кеше бит ул – аны эзләп килде, тапты. Урман эчендә калдырып та китә ала иде – кемдә кемнең ни эше бар: исәнме ул, юкмы. «Урманда адашып калды, тапмадым», – дияр иде. Бер көннән соң аны беркем дә искә алмаган булыр иде. Карале, күзне йомган килеш тә атлап була икән бит. Болай җайлырак та – аяклар йөри, күзләр ял итә. Иң мөһиме: чанага ныклап ябышырга, бармакларны ычкындырмаска...

Кар битне авырттырып бәрә, борынга, авызга тула. Зөләйха башын бераз күтәреп селкеп кагып алды. Үзе җиргә килеп төште, алда – ераклаша барган чана арты, әйләнә-тирәдә өзлексез кар бөтерелә. Сикереп торып, чананы куып җитте дә нык итеп артына ябышты. Өенә кайтып җиткәнче күзен ачмаска карар кылды.

Ишегалдына инде караңгы төшкәч кайтып керделәр. Утынны әрдәнә янына бушаттылар (Мортаза иртәгә ярачак), Сандугачны тугарып, чананы яшереп куйдылар.

Убырлы карчык ягындагы калын бәс каплаган тәрәзәдә ут юк. Зөләйха барыбер белә: каенана аларның кайтып кергәнен шундук сизде. Менә хәзерге минутта ук тәрәзә янында идән такталарының хәрәкәтенә колак салып тора ул: керү ишеге шапылдавыннан бу такталар башта ничек итеп сискәнеп китәрләр, ә аннары хуҗаның авыр адымнарыннан ничек итеп шыгырдый башларлар. Мортаза чишенеп юынгач, анисе ягына кереп китәчәк. Ул моны «кичке сөйләшү» дип атый. Чукрак карчык белән ни турында, ничек сөйләшеп була инде? Зөләйха моны һич аңламый. Шулай булса да, бу сөйләшүләр шактый озакка, хәтта сәгатьләр буена сузыла. Мортаза анисе яныннан тынычланып, канәгать булып чыга, хәтта елмаерга, шаяртып алырга да мөмкин.

Аларның бүгенге кичке сөйләшүләре Зөләйха өчен бик кулай булды әле. Ире, чиста күлмәген киеп, Убырлы янына кереп китүгә, Зөләйха җилкәсенә әле кибеп тә өлгермәгән толыбын салып, өйдән чыгып чапты.

Буран Юлбашны эре бөртекле каты кар белән каплаган. Зөләйха, башын дога укыгандагы кебек аска иеп, җилгә каршы урам буйлап бара. Өйләрнең керосин лампаларыннан төшкән сары яктылыктан ямь биреп җемелдәп торган кечкенә тәрәзәләре караңгыда әйбәтләп күренми дә.

Менә басу капкасына да килеп җитте. Биредә соңгы өйнең коймасы астында Юлбашка – койрыгы, басу кырына борыны белән басу капкасы иясе яши. Зөләйханың аны күргәне юк, әмма аны нык ачулы, мыгырдаучан, диләр. Ничек инде башкача булсын? Эше шундый бит: авылдан явыз рухларны куарга, аларны басу капкасыннан авылга үткәрмәскә, әгәр инде авыл халкының урман ияләренә дә үтенечләре туа икән – ярдәм итәргә, арадашчы булырга. Җитди эш бу – күңел ачып йөрү түгел.

→ Ахыры бар.

## Рөстәм хәзрәт Хәйруллин:

# «Хәмердән котылуның файдалы юлы – тәүбә итү»



**Узган елны республикада аракы эчеп үлүчеләрнең саны 356га җиткән. Әле бу үлүчеләр генә, хәмер эчү аркасында күпме гаилә таркала, балалар ятим кала, юл һәлакәтләре килеп чыга, җинаятьләр кылына. Татарстан мөфтие урынбасары, «Гаилә» мәчете имам хатибы Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН сүзләренчә, хәмер эчкән бәндәнең иманы кача, шуңа да Аллаһы Тәгалә безгә акылыбызны үзгәртә торган һәрбер исерткечне хәрам кылды.**

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА**

– Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең хәдис-шәрифләрендә аны чир дип әйтә. Әлеге авырудан дәваланырга кирәк, ди. Әмма ул гөнаһлы чир. Грипп яки башка авыруларны Аллаһы Тәгалә сынау итеп бирә, шуның белән безнең гөнаһларыбызны гафу итә. Ә алкоголизм чире гөнаһларыбызны арттыра гына.

**– Ә ул чир каян килеп чыга соң?**

– Шайтаннан, билгеле. Аны юкка гына шайтан суы дип атамаганнар бит. Шайтан шул агуы белән кешене эчәргә кыстый, акылын югалттыра, нәтиҗәдә үзе белән җәһәннәмгә алып бара. Аллаһы Тәгалә хәмерне шайтан гамәленнән булган бозык эш дип атый. Мәйдә сүрәсенең 90 нчы аятендә: «Әй сез, иман китергән бәндәләр! Аракы эчү, отыш уеннары, потларга табыну, юраулар – шайтан гамәленнән булган пычрак эшләрдер. Алардан саклаңыгыз, ерак торыгыз! Шаять, сез котылуга, җиңүгә ирешерсез», – диелә. Коръәндә Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә баштан, ул сезгә зыянлы, дип әйтә, аннары, чынлыкта зыяны файдасына караганда күбрәк, дип кисәтә. Аннан соң өченче тапкыр бер аятьтә, ул сезгә хәрам, ди.

**– Хәмер эчкән кешенең намазы кырык көн кабул булмый, диләр...**

– Бер сәхабә Пәйгамбәребездән, аракы эчкән кеше кырык көн дәвамында, димәк, намазын укымаска да тиешме, дип сорый. Пәйгамбәребез, намазны укырга тиеш, ул кабул ителә, әмма намаз өчен савабы язылмый, ди. Табиблар да, галимнәр дә каныбыздан спиртның чыгып бетүе өчен кырык көн кирәк булуын дәлилләде. Моннан мең ярым ел элек үк әйткән моны Пәйгамбәребез.

**– Табиблар дигәннән, кызыл шәрабны эчәргә кирәк, бигрәк тә ул хатын-кызлар өчен файдалы диючеләр дә бар.**

– Аннары, хатын-кызлар алкоголизмын дәвалап булмый, дип, чаң сугалар. Шайтан сине аз гына эчеп куйгач, тагын эч дип котырта бит. Шулай итеп эчкечегә әйләнүең дә бар. Кабатлап әйтәм, хәмернең файдасына караганда, зыяны күбрәк.

**– Хатын-кыз эчсә, гөнаһы да күбрәктер әле.**

– Гөнаһы күбрәк булмаса да, нәтиҗәсе күпкә аянычрак. Пәйгамбәребез, хатын-кыз ул – мәдрәсә, ди. Милләт аналары дип тә әйтәбез аларны. Ана кеше балалар тәрбияли – аның өстендә зур җаваплылык. Моның өчен ул рухи яктан да, физик яктан да сәламәт булырга тиеш. Ана кеше үзенең балалары өчен җаваплылык тоеп яшәсен, ялгыш адымнар ясаудан саклансын. Үзе исерек булган ана баласына ничек итеп аракы эчәргә ярамаганлыгын сөйләсен ди. Ул баласына үрнәк булырга тиеш.

**– Хәмерне эчүче генә түгел, аны җитештерүче дә, сатучы да гөнаһлы саналамы?**

– Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Аракыны ясаучы да, ясатучы да, сатучы да, саттыручы да, эчүче дә һәм эчерүче дә гөнаһлы була», – диде. Хәтта эчкән кеше янында да утырырга ярамый. Аларны Аллаһы Тәгалә ләгънәт итә.

**– Аракылы табынга утыру – гөнаһ, әмма туганың чакырган мәҗлескә бармый калсаң, төп сәбәп итеп шуны китерсәң, үпкәләргә дә мөмкиннәр. Андый вакытта нишләргә?**

– Дөрес әйтәсез, бу – бик катлаулы мәсьәлә. Диндә туганнар белән араны өзәргә ярамый дигән хәдис тә бар. Мондый очракта кайбер галимнәр ике табын әзерләргә куша, эчмәүчеләр хәмерсезенә утыра аласыз. Әмма бәйрәмнәрне аракысыз уздырсалар, күпкә хәерлерәк. Туган кешеләр дә акрынлап шуны аңлар, иншалла.

**– Составында спирт булган дару-төнәтмәләрне кулланырга ярыймы?**

– Әгәр дә ул даруларның спиртсызы гына бар икән, шуларны куллану хәерле. Ә инде аны эчмичә дәваланмаслык булсагыз, файдаланырга мөмкин. Ягъни сайлау варианты булмаганда, куллана аласыз. Дуңгыз итен дә бит бөтенләй ашарга булмаганда, ачтан үлмәс, җан саклап калу өчен аз гына кабып куярга ярый дигән. Яшәү белән үлем арасында булганда тыелмый.

**– Кеше исерек килеш үлеп китсә, ул үз-үзенә кул салучы кебек буламы?**

– Хәнәфи мәзхәбе буенча, мәет юыла, җеназа укыла, җеназаны имам кеше укымый. Әлеге вазифаны башка бер кеше башкара. Имам моны башкаларга сабак булсын өчен, тәрбияви максаттан шулай эшли.

**– Хәмердән котылу өчен нәрсә эшләргә кирәк?**

– Хәзер алкоголизмнан коткарам дигән рекламаларны күп күрергә була. Булышадыр ул чаралар да, әмма иң файдалы юл – тәүбә итү. Тәүбә ишеге һәрчак ачык. Кешенең бөтен дөнья кадәр гөнаһы булса да, ихластан сораса, Аллаһы Тәгалә аны кабул итә. Раббым, мине шушы чирдән азат кыл дип сорасаң, дәвасын бирер. Мәчеткә йөрергә, намаз укырга, ураза тотарга, шул рәвешле калебеңне чистартырга кирәк. Кыйблабызны төзәтергә беркайчан да соң түгел.

## Февраль аена намаз вакытлары

| Көн | Көн исеме | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Зәвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дүш | 05:29 | 06:08 | 07:38 | 11:56 | 12:00 | 14:24 | 16:16 | 18:03 |
| 2 | Сиш | 05:28 | 06:06 | 07:36 | 11:57 | 12:00 | 14:26 | 16:18 | 18:05 |
| 3 | Чәр | 05:26 | 06:04 | 07:34 | 11:57 | 12:00 | 14:28 | 16:20 | 18:07 |
| 4 | Пән | 05:25 | 06:02 | 07:32 | 11:57 | 12:00 | 14:30 | 16:22 | 18:08 |
| **5** | **Җом** | **05:23** | **06:00** | **07:30** | **11:57** | **12:00** | **14:32** | **16:24** | **18:10** |
| 6 | Шим | 05:21 | 05:58 | 07:28 | 11:57 | 12:00 | 14:34 | 16:26 | 18:12 |
| 7 | Якш | 05:20 | 05:56 | 07:26 | 11:57 | 12:00 | 14:36 | 16:29 | 18:14 |
| 8 | Дүш | 05:18 | 05:54 | 07:24 | 11:57 | 12:00 | 14:38 | 16:31 | 18:16 |
| 9 | Сиш | 05:16 | 05:52 | 07:22 | 11:57 | 12:00 | 14:40 | 16:33 | 18:18 |
| 10 | Чәр | 05:14 | 05:50 | 07:20 | 11:57 | 12:00 | 14:42 | 16:35 | 18:20 |
| 11 | Пән | 05:13 | 05:48 | 07:18 | 11:57 | 12:00 | 14:44 | 16:37 | 18:22 |
| **12** | **Җом** | **05:11** | **05:46** | **07:16** | **11:57** | **12:00** | **14:46** | **16:39** | **18:23** |
| 13 | Шим | 05:09 | 05:44 | 07:14 | 11:57 | 12:00 | 14:48 | 16:42 | 18:25 |
| 14 | Якш | 05:07 | 05:41 | 07:11 | 11:57 | 12:00 | 14:50 | 16:44 | 18:27 |
| 15 | Дүш | 05:05 | 05:39 | 07:09 | 11:57 | 12:00 | 14:52 | 16:46 | 18:29 |
| 16 | Сиш | 05:03 | 05:37 | 07:07 | 11:57 | 12:00 | 14:54 | 16:48 | 18:31 |
| 17 | Чәр | 05:01 | 05:35 | 07:05 | 11:57 | 12:00 | 14:56 | 16:50 | 18:33 |
| 18 | Пән | 04:59 | 05:32 | 07:02 | 11:57 | 12:00 | 14:58 | 16:53 | 18:35 |
| **19** | **Җом** | **04:56** | **05:30** | **07:00** | **11:57** | **12:00** | **15:00** | **16:55** | **18:37** |
| 20 | Шим | 04:54 | 05:28 | 06:58 | 11:57 | 12:00 | 15:02 | 16:57 | 18:39 |
| 21 | Якш | 04:52 | 05:25 | 06:55 | 11:57 | 12:00 | 15:04 | 16:59 | 18:41 |
| 22 | Дүш | 04:50 | 05:23 | 06:53 | 11:57 | 12:00 | 15:06 | 17:01 | 18:43 |
| 23 | Сиш | 04:47 | 05:21 | 06:51 | 11:56 | 12:00 | 15:08 | 17:03 | 18:45 |
| 24 | Чәр | 04:45 | 05:18 | 06:48 | 11:56 | 12:00 | 15:09 | 17:05 | 18:47 |
| 25 | Пән | 04:43 | 05:16 | 06:46 | 11:56 | 12:00 | 15:11 | 17:08 | 18:49 |
| **26** | **Җом** | **04:40** | **05:13** | **06:43** | **11:56** | **12:00** | **15:13** | **17:10** | **18:51** |
| 27 | Шим | 04:38 | 05:11 | 06:41 | 11:56 | 12:00 | 15:15 | 17:12 | 18:53 |
| 28 | Якш | 04:36 | 05:08 | 06:38 | 11:56 | 12:00 | 15:17 | 17:14 | 18:55 |
| 29 | Дүш | 04:33 | 05:06 | 06:36 | 11:55 | 12:00 | 15:19 | 17:16 | 18:57 |

## ДИНИ КАЛЕНДАРЬ

**2016 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр (мөселман ай календаре буенча 1437–1438 һиҗри еллар):**

**8 апрель** – Рәҗәб аеның беренче көне.
**14-15 апрель** – Рәгаиб кичәсе.
**3-4 май** – Мигъраҗ кичәсе;
**21 май** – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).
**21-22 май** – Бәраәт кичәсе;
**6 июнь** – Рамазан ае (Ураза) башланган көн;
**5 июль** – Ураза бәйрәме (гает);
**11 сентябрь** – Гарәфә көне;
**12,13,14 сентябрь** – Корбан бәйрәме;
**2 октябрь** – Һиҗри ел исәбе белән Яңа 1432 ел башланган көн. Мөхәррәм аеның 1 нче көне;
**11 октябрь** – Гашурә көне;
**11-12 декабрь** – Мәүлид бәйрәме.

## 1 ФЕВРАЛЬ – ДҮШӘМБЕ

### Татарстан – Яңа Гасыр
05:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
05:10 «Җомга киче». Концерт (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «За все тебя благодарю». Телесериал (12+)
10:00 «Сөй гомерне!». Телевизион спектакль (Г. Тукай әсәрләре буенча) (6+)
10:55 «Дин вә хәят» (6+)
11:00 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт (0+)
11:30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
12:00 «Александровский сад». Телесериал (16+)
13:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14:00 Новости Татарстана (12+)
14:15 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
14:55 «Тиззарядка» (0+)
15:00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Тамчы-шоу» (0+)
15:50 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «ТИН-клуб» (12+)
16:20 Мультфильмы (0+)
17:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17:35 «Сыргалым». Телесериал (12+)
18:30 Новости Татарстана (12+)
19:00 «Прямая связь» (12+)
20:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
20:30 «Татарлар» (12+)
21:00 «Күчтәнәч» (0+)
21:15 «Хочу мультфильм!» (0+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вечерняя игра» с Денисом Осокиным» (12+)
23:00 «Видеоспорт» (12+)
23:30 «Александровский сад». Телесериал (16+)
00:20 «За все тебя благодарю». Телесериал (12+)
01:10 «Сыргалым». Телесериал (12+)
02:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)

### РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.35 «Парламентские вести»
14.30, 17.30, 19.35 «Вести – Татарстан»

### ПЕРВЫЙ
5.00 Телеканал «Доброе утро»
9.00, 3.00 Новости
9.20, 4.20 Контрольная закупка
9.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55, 3.20 Модный приговор
12.00, 15.00 Новости с субтитрами
12.15 «Сегодня вечером» с Андреем Малаховым (16+)
14.20 «Таблетка» (16+)
15.15, 1.25 «Время покажет» (16+)
16.00 «Мужское / Женское» (16+)
17.00, 2.15, 3.05 «Наедине со всеми» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.45 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым (16+)
21.00 Время
21.30 Т/с «Мажор» (16+)

### РОССИЯ 1
5.00, 9.15 Утро России
9.00, 11.00, 14.00, 17.00, 17.50, 20.00 Вести
9.55 «О самом главном»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 Местное время. Вести-Москва
11.55 Т/с «Тайны следствия» (12+)
14.50 Вести. Дежурная часть
15.00 Т/с «Земский доктор» (12+)
18.15 «Прямой эфир» (16+)
21.00 Т/с «Солнце в подарок» (12+)
23.50 Честный детектив (16+)

### НТВ
5.00, 6.05 Т/с «Супруги» (16+)
6.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
7.00 «НТВ утром»
8.10 «Утро с Юлией Высоцкой» (12+)
9.00 Т/с «Возвращение Мухтара-2» (16+)
10.20 Т/с «Свет и тень маяка» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.20 Обзор. Чрезвычайное происшествие
14.00 Т/с «Братаны» (16+)
16.20 Т/с «Улицы разбитых фонарей» (16+)
18.00 «Говорим и показываем» с Леонидом Закошанским (16+)
20.00 Т/с «Пасечник» (16+)
22.00 «Итоги дня»

### КУЛЬТУРА
7.00 Евроньюс
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры
10.15, 1.40 «Наблюдатель»
11.15 Х/ф «Короли и капуста»
12.35 «Линия жизни»
13.30 Х/ф «Сын»
15.10 Х/ф «Аккаттоне»
17.10 Д/ф «Азорские острова. Ангра-ду-Эроишму»
17.25 «Примадонны мировой оперы
18.30 Д/ф «Лев Лунц и «Серапионовы братья»
19.15 «Спокойной ночи, малыши!»
19.45 «Главная роль»
20.05 «Сати. Нескучная классика...»
20.45 «Правила жизни»
21.15 «Тем временем» с Александром Архангельским

### РЕН ТВ
5.00, 4.30 «Территория заблуждений» с Игорем Прокопенко (16+)
6.00 «Пища богов» (16+)
7.00 «С бодрым утром!» (16+)
8.30, 12.30, 16.30, 19.30, 23.00 «Новости» (16+)
9.00 «Военная тайна» с Игорем Прокопенко (16+)
11.00 «Документальный проект» (16+)
12.00, 16.00, 19.00 «Информационная программа 112» (16+)
13.00 Званый ужин (16+)
14.00 Х/ф «Знаки» (16+)
17.00, 3.30 «Тайны Чапман» (16+)
18.00, 1.30 «Самые шокирующие гипотезы» (16+)
20.00 Х/ф «Джек -покоритель великанов» (12+)
22.00 «Водить по-русски» (16+)

### СТС
6.00 М/с «Лизун и настоящие охотники за привидениями» (12+)
6.35 М/с «Люди в чёрном» (0+)
7.30 М/с «Пингвинёнок Пороро» (0+)
7.55 М/с «Смешарики» (0+)
8.00 Т/с «Семейный бизнес» (16+)
10.00 «Мастершеф. Дети» (6+)
11.00 М/ф «Приключения Тинтина. Тайна «Единорога» (12+)
13.00 Шоу «Уральских пельменей» (16+)
13.30, 18.30, 0.00 «Уральские пельмени» (16+)
14.00 Х/ф «Сокровище нации» (12+)
16.15 Х/ф «Сокровище нации. Книга тайн» (12+)
19.00 «Миллион из Простоквашино» с Николаем Басковым (12+)
19.05, 19.30 Т/с «Мамочки» (16+)
20.00 Т/с «Воронины» (16+)
21.00 Т/с Премьера! «Молодёжка» (16+)

### ЗВЕЗДА
6.00 Д/с «Оружие XX века» (12+)
6.25 Служу России!
6.55 Новости. Главное
7.35 Х/ф «Я – Хортица» (6+)
9.00, 13.00, 18.00, 22.10 Новости дня
9.20, 10.05 Х/ф «Безотцовщина» (12+)
10.00, 14.00 Военные новости
11.20, 13.15 Т/с «Главный калибр» (16+)
13.40, 14.05 Т/с «Крот» (16+)
18.30 Д/с «Сталинградская битва» (12+)
19.20 «Специальный репортаж» (12+)
19.40 «Научный детектив» (12+)
20.05 Т/с «Военная разведка. Первый удар» (12+)
22.35 Х/ф «Инспектор ГАИ» (12+)

### Матч ТВ
6.30 Д/с «Второе дыхание» (16+)
7.00, 9.00, 10.00, 11.00, 11.35, 12.00, 13.50, 15.00 Новости
7.05, 15.10, 23.15 Все на Матч!
9.05 «Ты можешь больше!» (16+)
10.05 «Где рождаются чемпионы?» (16+)
10.30, 2.00 Д/с «Вся правда про...» (16+)
11.05 Д/с «Первые леди» (16+)
11.40 Специальный репортаж
12.05 Х/ф «Миннесота» (16+)
14.00 «Безумный спорт с Александром Пушным» (12+)
14.30 «Я -футболист» (12+)
15.55 Хоккей. «Авангард» (Омская область) – «Торпедо» (Нижний Новгород). КХЛ. Прямая трансляция
18.15 «Континентальный вечер»
19.15 Хоккей. СКА (Санкт-Петербург) – «Йокерит» (Хельсинки). КХЛ. Прямая трансляция
21.45 Футбол. «Зенит» (Россия) – «Брондбю» (Дания). Международный турнир «Atlantic Cup 2016». Трансляция из Португалии
0.00 Хоккей с мячом. Россия -Казахстан. Чемпионат мира
2.30 Х/ф «Скорость» (12+)

## 2 ФЕВРАЛЬ – СИШӘМБЕ

### Татарстан – Яңа Гасыр
05:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
05:10 «Мәдәният дөньясында» (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «За все тебя благодарю». Телесериал (12+)
10:00 «Сыргалым». Телесериал (12+)
11:00 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт (0+)
12:00 «Александровский сад». Телесериал (16+)
13:00 «Секреты татарской кухни» (12+)
13:30 «Размышления о вере. Путь к исламу» (6+)
13:35 «Путь» (12+)
14:00 Новости Татарстана (12+)
14:15 «Музыкаль каймак» (12+)
14:55 «Тиззарядка» (0+)
15:00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
15:55 «Tat-music» (12+)
16:10 Мультфильмы (0+)
17:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17:35 «Сыргалым». Телесериал (12+)
18:30 Новости Татарстана (12+)
19:00 «Народный контроль» (12+)
19:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
20:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
20:30 «Татарлар» (12+)
21:00 «Күчтәнәч» (0+)
21:15 «Хочу мультфильм!» (0+)
21:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
22:00 «Вечерняя игра» с Миляушой Таминдаровой» (12+)

### РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Современник». Зуфар Фаткутдинов
9.25 «Город мастеров»
9.50 «Киноафиша»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 «Вести -Татарстан»

### ПЕРВЫЙ
5.00 Телеканал «Доброе утро».
9.00, 3.00 Новости.
9.20, 4.15 Контрольная закупка
9.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55, 3.15 Модный приговор
12.00, 15.00 Новости с субтитрами
12.15, 21.35 Т/с «Мажор» (16+)
14.25 «Таблетка» (16+)
15.15 «Время покажет» (16+)
16.00 «Мужское / Женское» (16+)
17.00 «Наедине со всеми» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.45 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым (16+)
21.00 Время

### РОССИЯ 1
5.00, 9.15 Утро России
9.00, 11.00, 14.00, 17.00, 17.50, 20.00 Вести
9.55 «О самом главном»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 Местное время. Вести-Москва
11.55 Т/с «Тайны следствия» (12+)
14.50 Вести. Дежурная часть
15.00 Т/с «Земский доктор» (12+)
18.15 «Прямой эфир» (16+)
21.00 Т/с «Солнце в подарок» (12+)

### НТВ
5.00, 6.05 Т/с «Супруги» (16+)
6.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
7.00 «НТВ утром»
8.10 «Утро с Юлией Высоцкой» (12+)
9.00 Т/с «Возвращение Мухтара-2» (16+)
10.20 Т/с «Свет и тень маяка» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.20 Обзор. Чрезвычайное происшествие
14.00 Т/с «Братаны» (16+)
16.20 Т/с «Улицы разбитых фонарей» (16+)
18.00 «Говорим и показываем» с Леонидом Закошанским (16+)
20.00 Т/с «Пасечник» (16+)
22.00 «Итоги дня»
22.30 Т/с «На глубине» (16+)
0.20 Т/с «Глухарь. Продолжение» (16+)
2.25 Главная дорога (16+)

### КУЛЬТУРА
6.30 Евроньюс
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры
10.15, 1.55 «Наблюдатель»
11.15 Х/ф «Короли и капуста»
12.20 Д/ф «Армен Джигарханян»
13.05 Д/ф «Кастель-дель-Монте. Каменная корона Апулии»
13.20, 20.45 «Правила жизни»
13.50 «Пятое измерение»
14.15, 0.50 Д/с «Весёлый жанр невесёлого времени»
15.10, 23.50 Юрий Лотман. «Пушкин и его окружение»
16.10 «Сати. Нескучная классика...»
16.50 «Острова»
17.30 «Примадонны мировой оперы
18.15 Д/ф «Семен Райтбурт»
19.15 «Спокойной ночи, малыши!»
19.45 «Главная роль»
20.05 Искусственный отбор
21.15 «Игра в бисер» с Игорем Волгиным
22.00 Д/ф «Тельч. Там, где дома облачены в праздничные одеяния»
22.15 «Рэгтайм, или Разорванное время»
22.45 Д/с «Холод»
23.45 Худсовет
1.30 Д/ф «Александр Вишневский. Осколок в сердце»

### РЕН ТВ
5.00, 4.30 «Территория заблуждений» с Игорем Прокопенко (16+)
6.00 «Пища богов» (16+)
7.00 «С бодрым утром!» (16+)
8.30, 12.30, 16.30, 19.30, 23.00 «Новости» (16+)
9.00 «Военная тайна» с Игорем Прокопенко (16+)
11.00 «Документальный проект» (16+)
12.00, 16.00, 19.00 «Информационная программа 112» (16+)
13.00 Званый ужин (16+)
14.00 Х/ф «Джек – покоритель великанов» (12+)
17.00, 3.30 «Тайны Чапман» (16+)
18.00, 1.30 «Самые шокирующие гипотезы» (16+)
20.00 Х/ф «Беовульф» (16+)
22.00 «Водить по-русски» (16+)
23.25 Т/с «Рэй Донован» (18+)
2.30 «Секретные территории» (16+)

### СТС
6.00 М/с «Лизун и настоящие охотники за привидениями» (12+)
6.35 М/с «Люди в чёрном» (0+)
7.30 М/с «Пингвинёнок Пороро» (0+)
7.55 М/с «Смешарики» (0+)
8.05 Т/с «Зачарованные» (16+)
9.00 «Ералаш» (0+)
10.25 Х/ф «Крошка из Беверли-Хиллз» (0+)
12.05, 14.00 Шоу «Уральских пельменей» (16+)
13.30, 0.00 «Уральские пельмени» (16+)
15.00, 20.00 Т/с «Воронины» (16+)
17.00 Т/с «Кухня» (16+)
19.00 «Миллион из Простоквашино» с Николаем Басковым (12+)
19.05 Т/с «Мамочки» (16+)
21.00 Т/с Премьера! «Молодёжка» (16+)
22.00 Т/с Премьера! «Выжить после» (16+)
23.00 Т/с Премьера! «Кости» (16+)
0.30 Х/ф «Как украсть бриллиант» (12+)
2.20 Х/ф «Легко не сдаваться» (16+)

### ЗВЕЗДА
6.00 Д/с «Оружие XX века» (12+)
6.25, 9.15, 13.40, 14.05 Т/с «Крот» (16+)
9.00, 13.00, 18.00, 22.10 Новости дня
9.50, 10.05, 20.05 Т/с «Военная разведка. Первый удар» (12+)
10.00, 14.00 Военные новости
12.00 «Процесс» (12+)
13.15 «Специальный репортаж» (12+)
18.30 Д/с «Сталинградская битва» (12+)
19.20 «Легенды армии» с Александром Маршалом (12+)
22.35 Х/ф «Расписание на послезавтра» (0+)
0.15 Х/ф «На острие меча» (12+)
1.55 Х/ф «Город зажигает огни» (0+)
3.50 Х/ф «Я – Хортица» (6+)
5.10 Х/ф «Эй, на линкоре!» (6+)

### Матч ТВ
6.30 Д/с «Второе дыхание» (16+)
7.00, 9.00, 10.00, 11.00, 12.00 Новости
7.05, 15.00, 20.45, 0.40 Все на Матч!
9.05, 4.30 «Ты можешь больше!» (16+)
10.05 «Где рождаются чемпионы?» (16+)
10.30 Д/с «Вся правда про...» (16+)
11.05 «Дублер» (12+)
11.30 «Анатомия спорта» с Эдуардом Безугловым (16+)
12.05 Д/ф «Путь бойца» (16+)
12.30 Х/ф «Али» (16+)
15.35 Специальный репортаж (16+)
15.55 Хоккей. Суперфинал «Лиги Легенд». Финал
17.55 Д/ф «Павел Буре. Русская ракета»
18.55 Хоккей с мячом. Россия – Финляндия. Чемпионат мира. Прямая трансляция
21.30 Д/с «Сердца чемпионов» (16+)

## 3 ФЕВРАЛЬ – ЧӘРШӘМБЕ

### Татарстан – Яңа Гасыр
05:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
05:10 «Караоке бәйге» (6+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «За все тебя благодарю 2». Телесериал (12+)
10:00 «Сыргалым». Телесериал (12+)
10:55 «Дин вә хәят» (6+)
11:00 «Оныта алмыйм...». Ретро-концерт (0+)
11:30 «Халкым минем...» (12+)
12:00 «Александровский сад». Телесериал (16+)
13:00 «Среда обитания» (12+)
13:30 Документальный фильм (12+)
14:00 Новости Татарстана (12+)
14:20 «Каравай» (12+)
14:55 «Тиззарядка» (0+)
15:00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Без – Тукай оныклары» (0+)
15:45 «Һөнәр» (6+)
15:50 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:05 Мультфильмы (0+)
17:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17:35 «Сыргалым». Телесериал (12+)
18:30 Новости Татарстана (12+)
19:00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак Барс» – «Сибирь».
Трансляция из Казани (12+)
21:15 «Күчтәнәч» (0+)
21:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
22:00 «Вечерняя игра» с Марком Оффенгенденом» (12+)
23:00 «Видеоспорт» (12+)
23:30 «Александровский сад». Телесериал (16+)
00:20 «За все тебя благодарю 2». Телесериал (12+)
01:10 «Сыргалым». Телесериал (12+)
02:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
03:40 «Халкым минем...» (12+)
04:05 «Яшьләр тукталышы» (12+)
04:30 «Оныта алмыйм...». Ретро-концерт (0+)

### РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 «Вести – Татарстан»

### ПЕРВЫЙ
5.00 Телеканал «Доброе утро»
9.00, 3.00 Новости
9.20, 4.20 Контрольная закупка
9.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55, 3.20 Модный приговор
12.00, 15.00 Новости с субтитрами
12.15 Т/с «Мажор» (16+)
14.25 «Таблетка» (16+)
15.15 «Время покажет» (16+)
16.00 «Мужское / Женское» (16+)
17.00, 2.30, 3.05 «Наедине со всеми» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами
